АЛГА ЫРГЫЛУ
Россия төбәкләрендә инвестицион климат торышы рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Мәскәүне генә уздырган
> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Рәисе имзалаган яңа законнар
> 3

ЯҢАДАН ТУУ
Ирекkә чыккан кешегә яңа тормышка аяк басканда ничек ярдәм итәргә?
> 5

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр биредә
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 85 (29052) | Шимбә | 17 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖӘЙНЕҢ ТАТЛЫ СЫЕ

РЕСПУБЛИКАДА БАКЧА ҖИЛӘГЕ КАЙЛАРДА САТЫЛА?

Көннәр кояш, җылылык белән артык иркәләмәсә дә, җиләк исе чыга башлады. Эре хуҗалыклар бакча җиләгенең беренче уңышын җыя. Димәк, чын-чынлап җәй җитте дип әйтергә җирлек бар. Татарстанда кайсы хуҗалыкларда бакча җиләге үстерәләр? Без шуны белештек.

vk.com

Җиләк үстерүчеләр әйтүенчә, быел татлы ризык азрак һәм ваграк. Моңа, бердән, май башындагы суыклар сәбәпче булса, икенчедән, корылык та үзенекен итте. Кырау сугып, шактый уңыштан коры калган хуҗалыклар да бар.

Ә менә Буа районының Бик-Үти авылында Миләүшә һәм Җәмил Дәүләтшиннар хуҗалыгында беренче уңышны инде майда ук җыеп алганнар. Кызлары Лилия әйтүенчә, гаилә җиләкчелек белән дүрт ел шөгыльләнә. Бер гектар җирдә җиләкнең җиде төрле сортын үстерәләр. Киләчәктә тулысынча алмалар үстерүгә күчеп, җиләкчелек белән шөгыльләнүне туктатырга да исәплиләр икән.

– Узган ел беренче уңышны июнь ахырларында гына җыйган булсак, быел майда ук керештек. Май башындагы суыклар иртә өлгерә торган сортларның чәчәкләрен кыырды. Ул өлешләрдә уңыш аз һәм, гомумән алганда, быел җиләк вак, – диде Лилия.

Аның сүзләренчә, һәр елдагыча, җиләкне сатып алырга теләүчеләр күп. «Кая куясы икән?» – дип мәшәкатьләнмиләр, киресенчә, ничек өлгертергә белмиләр. Узган елларда кешеләр җиләкне үзләре дә килеп җыйса, быел фермерлар бары тик җыеп кына бирә. Килограммын 300–350 сумга саталар.

Минзәлә районының Яңа Александровка авылында «Ягодар» җиләк фермасы хуҗасы Ринат Сәлимгәрәев әйтүенчә, алар беренче уңыштан әле шушы көннәрдә генә авыз иткәннәр.

– Җиләк өчен бөтенләй уңышсыз ел дип әйтеп булмый, тик узган ел белән чагыштырганда, ул ике тапкыр азрак. Быел иртә чәчәк аткан җиләкләрне кырау сукты. Безгә зур зыян килмәде үзе, тик Түбән Кама районындагы хуҗалык мәйданнарының 70 процентында үсүче җиләкләрне кырау суккан, – диде Ринат Сәлимгәрәев.

Әлеге хуҗалыкта җиләктән тыш, кара бөрлегән һәм кура җиләге, карлыган да үсә. Җиләкнең бер килограммын 500 сумнан саталар. Кешеләр үзләре килеп җыеп алган очракта, килограммын 420 сумнан бирәләр.

Биектау районының Айбаш авылында да җиләк үстерәләр. Тик быел биредә уңыш бик аз булган.

– Әлеге мәйданны киләсе елга бетерербез, дип торабыз, – диде фермер Руслан Шакиров. – Яңгыр юк, су сиптерүне дә көйләү мөмкин түгел, үсентеләр дә картайды. Шуңа күрә уңыш бик аз быел. Өй янында зур булмаган кишәрлектә, сынап карау максатыннан, җиде төрле сорттагы җиләк утыртып карадык. Киләчәктә шуларның иң уңышлысын сайлап алып, яңа мәйданнарда утыртырга телибез.

Җиләкне үзләре килеп җыярга теләүчеләргә 250 сумнан бирәләр. Тик кешеләргә алдан белешеп, шалтыратып килергә киңәш итте Руслан Шакиров.

– Башка елларны җиләк Краснодардан күп килә торган иде. Быел анда һава шартлары уңай булмады, шунлыктан үзебездә үсүче җиләкләрнең дә бәяләре арзан булмас дип фаразлыйм, – диде эшмәкәр.

Чүпрәле районы эшмәкәре Альфред Хәйруллин – республикада бакчачылык белән иң уңышлы шөгыльләнүче фермерларның берсе. Бүген ул зур мәйданнарда җир җиләге, кура җиләге, карлыган, алмагач үстерә. Уңышны исә беренчеләрдән булып бакча җиләге бирә. Дүрт-биш көн элек зур күләмдә җиләк җыеп алырга өлгергәннәр дә инде.

– Безнең якларда уңыш азрак, үземнекен әлегә әйтү авыр, җиләкләр пешә генә башлады әле. Тик сезонны ачык дип игълан итәргә була. Шулай да җиләкнең вакыты кыска аның. Ике атна дигәндә бетеп тә китә. Яңа утырткан үсентеләрдә җиләкләр яхшы гына күренә. Минем сату белән бервакытта та авырлык булганы юк. Әле менә Мәскәүдән күпләп җыеп алып китәргә телиләр. Бүген Ульяновскига беренче машинаны озаттык, – диде Альфред Хәйруллин.

Хуҗалык бакча җиләгенең бер килограммын 350–400 сумга сата.

ТАТАРСТАНДА ҖИЛӘК ҮСТЕРҮЧЕ БАШКА ХУҖАЛЫКЛАР

- «Җиләк аланы» («Ягодная долина») хуҗалыгы (Әлмәт районының Ямаш авылы, Яшел Үзән районының Зур Яке авылы). Җиләкнең бер килограммы – **500 сум**.
- «Ялалетдинов» фермер хуҗалыгы (Кама Тамагы). Җиләкнең бер килограммы – **450 сум**.
- «ТатЯгода» хуҗалыгы (Яшел Үзән районының Олы Карагуҗа авылы). Җиләк бәяләре – **350–500 сум**.
- Яшел Үзән районының Зур Яке авылындагы фермер хуҗалыгында да җиләкне бары тик үзләре генә җыеп сата. Килограммы – **350 сум**.

Марат Садыйков исемен йөртәчәк

Казан шәһәре 7 нче хастаханәсенә Татарстанның элекке сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков исеме бирелгән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, сәламәтлек саклау министры, Татарстан Республикасының атказанган табибы Садыйков Марат Наил улының истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән, республика Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре 7 нче хастаханәсенә Марат Садыйков исемен бирү тәкъдимен кабул итәргә карар бирә», – диелгән документта. Сәламәтлек саклау министрлыгы 60 көн эчендә хастаханәнең уставын үзгәртергә тиеш.

Исегезгә төшерәбез: Марат Садыйков быел гыйнвар аенда 53 яшендә вафат булды.

Белеп ял итәсе

Татарстанда 5 комлык гигиена таләпләренә җавап бирми. Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, Нурлат, Мамадыш, Лаеш һәм Лениногорск, шулай ук Кама Тамагы районнарындагы комлыклар микробиологик күрсәткечләр буенча тиешле таләпләргә туры килми. Лаештагысының исә санитария-химия күрсәткечләре начар.

Районнар хакимиятләре һәм җаваплы кешеләргә бу пляжлар янындагы суда коенуның тыелуы турында белдерүләр урнаштыру тәкъдимнәре юлланган. Роспотребнадзор идарәсе дә әлеге территорияләрдә ял итмичә торырга киңәш итә.

Казанда яшәүчеләр исә «Нижнее Заречье» комлыгының ял итүчеләрне кабул итәргә әзер булмавына зарлана. Гәрчә бу пляж инде ачылса да. Комлык чүп-чардан арындырып бетерелмәгән, мәгълүмат плакатлары урнаштырылмаган. Әлегә биредә су коенуның тыелуы турында билге һәм кара төстәге флагны гына күрергә мөмкин.

2 июньгә алынган мәгълүматлар буенча, Татарстанда 26 пляж ачылган.

Батырлык өчен

Махсус хәрби операция башланганнан бирле Украина Кораллы көчләренең хәрби техникасын юк иткән яки кулга төшергән өчен Россиянең 10 меңнән артык хәрбие 50 меңнән 300 мең сумга кадәр махсус түләү алган. Бу хакта Россия Оборона министрлыгы хәбәр итә.

Быел юк ителгән 45 вертолет һәм 71 самолетның һәрберсе өчен 300 мең сум акча түләгәннәр. Хәрбиләр юк иткән йөзләгән бронетанк техникасының һәрберсе өчен йөзәр мең сум алган.

Хәрби ведомство мәгълүматларына караганда, быел 5 айда Украина һәм Көнбатыш илләренең 4,4 мең берәмлек хәрби техникасы юк ителгән. Моның өчен Россиядән 3193 хәрби түләү алды. Ә узган ел 11586 берәмлек техниканы юк иткән өчен 7064 кешегә акча түләнгән.

Вазгыять

Үтәлмәгән кагыйдә

Татарстан юлларында фаҗигаләр саны арткан, һәлак булучылар кимегән. Һәр очрак гомере өзелгән кешенең якыннары өчен фаҗига. Татарстанның юл хәрәкәте иминлеге буенча баш дәүләт инспекторы Рөстәм Гарипов журналистлар белән очрашуда янә күптәнге хакыйкатьне искә төшерде: иминлек өчен һәркем җаваплы!

Татарстан юлларында куркыныч саннар

	2023 елның 5 аенда	Узган ел белән чагыштырганда
Юл һәлакәтләре	1196	+ 34
Үлүчеләр	85	– 20
Имгәнүчеләр	1458	+ 16

Быелның биш аенда республикада 1196 юл һәлакәте килеп чыккан. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 34 очракка күбрәк. Аварияләр иң күп арткан районнар исемлегендә Бөгелмә, Яшел Үзән һәм Биектау бар.

– Узган елның шул ук чорында Татарстан юлларында гомере өзелгәннәр 20гә күбрәк булган. Хәвефле саннар кимесә дә, юлларда якынын югалткан гаилә өчен аларның һәркайсы бик зур фаҗига, – ди Рөстәм Гарипов.

Ел башыннан бирле Татарстан юлларында дүрт баланың гомере өзелгән. Икесе юлда машинага утырып барганда, тагын икесе шәһәр җирендә юл аша чыкканда һәлак булган. Быелның гыйнвар – май аралыгында республикада балалар катнашында 159 юл һәлакәте теркәлгән. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 14 очракка күбрәк.

Рөстәм Гарипов бу урында ата-аналар колагына даими әйтелеп килгән сүзләрне кабатларга мәҗбүр булды. Машинада барганда бала махсус утыргычта булырга тиеш! Яшерен-батырын түгел, бүген ата-аналарның күбесе аны иминлек өчен түгел, ә инспекторлар штраф язмасын өчен йөртә. Юкса андый утыргычның үлем-китем очракларын – 54 процентка, имгәнү ихтималын 76 процентка киметүе күптән расланган.

Татарстанның баш дәүләт автоинспекторы баланы мопед, мотоцикл ише кәттә «тимер ат»ка утыртыр алдыннан да җиде кат уйларга куша. Әле июнь башында гына Спас районында аздан гына фаҗига булмыйча калды. Инспекторлар Чәчәкле авылында берүзе квадроциклда җилдергән 4 яшьлек баланы (!) туктаткан. Малай шәһәрдән әбисенә кунакка кайткан булган.

– Кайбер ата-ананың ваемсызлыгына шаккатарлык, – ди Рөстәм Гарипов.

Баш инспектор исерек машина йөртүчеләргә аерым тукталды. Андый кешенең исерек килеш рульгә утырганын күрсәң, ачкычын тартып алырга, аны туктатып калырга тырышырга, ул да булмаса, ЮХИДИ хезмәткәрләренә хәбәр итәргә кирәк, дип саный подполковник Гарипов.

ЮХИДИ инспекторлары җәяүлеләрне дә уяу булырга чакыра. Барыннан да бигрәк, юлны тиеш булмаган урыннан чыккан, юл аша чыкканда телефоныннан аерыла алмаучылар колагына әйтелгән сүз бу. Ник дигәндә, ел башыннан бирле республикада теркәлгән юл һәлакәтләренең өчтән бере нәкъ менә җәяүлеләр гаебе белән килеп чыккан. Биш ай эчендә 109 һәлакәттә 19 кешенең гомере өзелгән.

– Машина ул – техника. Ул ватык булырга яки аны йөртүче исерек, наркоман булырга, рульдә барганда йоклап китәргә мөмкин. Юл аркылы чыкканда шул турыда уйларга кирәк, – ди Рөстәм Гарипов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Виталий МУТКО, Россиянең элеккеге спорт министры:

Казанның үсешендә спорт чараларының да өлеше зур. Минтимер Шәймиев, Рөстәм Миңнеханов та зур эш башкарды. «Барселона» белән уйнаганда, «Рубин» уенчылары туп керткәч, Минтимер Шәрипович: «Менә күрдеңме, нәрсә эшләргә кирәк», – дигән иде. Шуннан соң барысы да Казан белән кызыксына башлады. Анда барысы да кул белән эшләнгән. Без килгәндә, анда берни юк иде әле.

(Петербург халыкара икътисадый форумында сөйләгәннәрдән)

РОССИЯДӘ – ТУРИЗМ



Бу җәйдә туристлар Россия буйлап сәфәр кылганда яшәү урыны өчен тәүлегенә уртача 4160 сум акча тота икән. Бу – узган ел белән чагыштырганда 13 процентка күбрәк. Бу хакта «Суточно.ру» онлайн сервисы белгечләре хәбәр итә.

ТУРИСТЛАР АРАСЫНДА ПОПУЛЯР ШӘҺӘРЛӘР ҺӘМ АЛАРДА ТОРАК БӘЯЛӘРЕ*

Санкт-Петербург	4520 сум	Зеленоградск	5430 сум
Сочи	5200 сум	Адлер	4330 сум
Мәскәү	4250 сум	Геленджик	4750 сум
Калининград	3140 сум	Сириус	5850 сум
Казан	3730 сум	Кисловодск	3300 сум

*бер тәүлеккә

Шәкерткә ярдәм

Татарстан Диния нәзарәте «Зәкят» хәйрия фондының республикадагы мөселман уку йортларына финанс ярдәм күрсәтү буенча онлайн хезмәте эшли башлады. Фонд сайтында барлыкка килгән «Мәдрәсәгә игелек кыл» сервисы 8 мәдрәсә, РИИ һәм КИУ файдасына читтән торып сәдака һәм зәкят бирү мөмкинлеге бирә.

Теләгән һәркем әлеге уку йортлары үсешенә матди яктан ярдәм итә ала. Моның өчен сервиста аларның берсен сайлап алып, акча җибәрергә була. Хәйрия акчасы мәдрәсәләрне матди яктан тәэмин итү, мөгаллимнәр һәм шәкертләргә ярдәм күрсәтү, кирәкле әдәбият сатып алу, биналарны төзекләндерү, тукландыру чыгымнары өчен тотылачак.

Татарстанның мөселман уку йортларында татар, рус һәм гарәп телле имамнар һәм мөгаллимнәр, мөселман, иҗтимагый, дәүләт оешмалары, дөньяви һәм дини уку йортлары өчен кадрлар әзерлиләр.

«Татар-информ»

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Бәдәвилеккә таба

Без яшәгән планета акрын гына чүлгә әйләнеп бара. Ел саен коры, шыксыз, флора һәм фауна үтә дә ярлы, уңдырышсыз булган җирләрнең мәйданы арта тора. Ник арта? Галимнәр бу күренешне беренче чиратта кеше заты, аның масштаблы эшчәнлеге, табигатькә чамасыз тыкшынуы, табыш артыннан куган корпорацияләрнең табигать белән санлашмавына бәйли. Бу хакта сүз кузгатуның сәбәбе шунда: нәкъ бүген, ягъни 17 июнь – Чүлгә әверелү һәм корылыкка каршы халыкара көрәш көне билгеләп үтелә.

Сәер җан ияләре без. Адәми зат үзе үз кыбырсулары тудырган проблемаларны күрә, аларның яхшыга илтмәвен аңлый, шул хакта сөйли, тик корткычлык алып барудан туктарга җыенмый. Табигатькә зыян салу бетсен өчен, зурдан кубып ул берни дә эшләми яисә бик аз эшли. Ул, ягъни кешелек күбесенчә бүген белән, бүгенгенең тар мәнфәгатьләрен кайгыртып яши. Бу хәл сәерлектән дә бигрәк сансызлык, акылсызлык түгел микән? «17 июньгә махсус дата билгеләгәннәр, чара оештырганнар, ул юнәлештә нидер эшләгәннәр күпме, ничә процент икән?» дигән сорау туа. Ихтимал, гафу ителмәслек дәрәҗәдә аздыр. Бу да – сансызлык билгесе.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) 1994 елның 17 июнендә дәүләтләр, аларның җитәкчеләренә җирләрнең яраксызга әйләнүенә, корылыкка каршы чаралар күрә башларга кушкан Конвенция тарата, проблеманың җитдилеген җиткерә. Җитәкчеләрнең күбесе аны ала, укый һәм дә… ерак папкага салып куя. Кем инде ул БМО? Аның армиясе бармы, үзсүзләнгән өчен санкцияләр кертә, икътисадый басым ясый аламы? Берсе дә юк. БМО бары җаваплы булырга, киләчәк турында кайгыртырга, акылга килергә генә өнди ала, аның башка вәкаләтләре юк. Ә дәүләт җитәкчеләренең күбесе шундый, алар көч, басым белән генә исәпләшә. Аларның инсафлылары да үзләрен бары үз иле өчен генә җаваплы тоя. Гомумкешелек проблемалары алар өчен унынчы урында. БМО дигәндә тагын шунысын да искәртик: аның генераль секретаре булган Антониу Гутерриш узган елны: «Кешелек кызу адымнар белән климатик тәмугка атлый, без бик тиздән һава торышында чамасыз кискенлек, хаос башланачак критик ноктага җитәчәкбез» , – дигән иде. Мондый белдерүдән соң дөнья илләре дәррәү углеводородлар ягуны чикли, урманнарны күпкә кимрәк кисә, ашыгып башка чаралар күрә башлады дип уйлыйсызмы? Нык ялгышасыз.

2010 елгы корылыкны хәтерлисездер. Безнең зур булмаган шәһәр, анда яшәүчеләр алдына ул елны эчәргә яраклы су проблемасы килеп басты. Шәһәр халкын су белән тәэмин итеп торган чишмәләр кибегә, аларда су бетә башлау аркасында. Шәһәргә нигез салынганнан бирле андый хәл күзәтелмәгән. Ул ел – мин белгән бәрәңгесез калган бердәнбер ел, дияр идем, 2021 елда да «икенче икмәк» дигәнебез тавык йомыркасының сарысы зурлыгында гына булды. Гомумән дә республиканың көньяк-көнчыгышында соңгы ике дистә елда яңгырлар аз ява, җәй коры килә. Бер бездә генә микән? Татарстан гидрометеорология һәм әйләнә-тирәне күзәтү идарәсе җитәкчесе Сергей Захаров шушы атнада мәгълүм электрон басмага биргән интервьюда соңгы 50 ел эчендә республикадагы уртача температураның 2 градуска артуын әйтте. Бу – шактый җитди күрсәткеч.

Глобаль җылыну, аның сәбәпләре – углеводородларны чамасыз күләмдә ягу аркасында туган парник эффекты турында язып торабыз. Чүлләр мәйданы артуда ул күренешнең роле ифрат та зур. Тик чүл дигәч тә, комнан, тоташ барханнардан гына торган мәйданнарны күз алдына китерү кирәкми. Туфракның теләсә нинди деградациясе, үсемлек үсми торган халәткә җитүе – олы бәла, андый җирләрнең чүлдән аермасы аз. Ул хәлгә төшүдә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүдәге бүгенге интенсив алымнар – ашламаларны, төрле пестицидларны артыгын куллану, агрокультураларны дөрес икмәү, туфракның җелеген суыру ята. Сөрүлек җирләр эрозиягә аеруча тиз бирешә: җил, явым-төшемнәр аркасында туфракның өске, уңдырышлы өлеше, андагы гумус тузанга әйләнә, юыла, елгаларга төшә. Геологлар, океанга агып киткән туфрак күләмен елына 25 млрд тонна тирәсе, дип билгеләп. Ә яраксызга әйләнгән җирләр мәйданы, кайбер чыганакларга ышанганда, ел саен 1,5 млн квадрат километрга (!) артып тора. Биредә без бик исәпкә алмаган сәбәпләр: табигый көтүлекләрдәге терлекләр саны күбәю, сазлыкларны киптерү, табигый ресурслар чыгарганда туфракны пычрату кебек факторлар да үз өлешен кертә, диләр.

Бүгенге кешелек – башлыча автомобильләр белән мыжгып торган, сәнәгать предприятиеләре күп булган олы шәһәрләрдә, мегаполисларда яшәүче цивилизация. Шәһәрләр саны арту, анда яшәүчеләр күбәю – урбанизация, табигатькә зыян салмау, дигәндә бер дә яхшыга түгел. Мегаполислар – табигать-ана тәнендәге зурая баручы яралар алар. Тирә-юньне, атмосфераны пычрату, парник эффекты, дигәндә – рекордчылар. Бүген җирдә, язуларына караганда, халык саны миллионнан арткан 446 шәһәр бар. 5 миллион, аннан да күбрәк кеше яшәгән калалар да 50дән арткан. Чунцин дигән Кытай шәһәренең үзендә генә 30 миллион кеше яшәве мәгълүм. Уртача зурлыктагы тулы бер ил! Ә бит табигать белән гармониядә яшим дигәндә, киресенчә, кече шәһәрләр һәм авылларга йөз тоту, мегаполислар тудырмау зарур. Юк, ниндидер үҗәтлек белән кеше дигәнең нәкъ киресен эшли…

Аерым илләрдә, глобаль җылынуга, корылыкка каршы чаралар күрәсе урында, климат үзгәрүгә җайлашу буенча план-программалар хәстәрли башлаганнар, дигән хәбәрләр дә бар. Ягъни сәбәпләрне күрмәмешкә салышып, нәтиҗәләр белән бил алышу. Әлбәттә, чүлдә оазислар оештырып, бүлмә, торак саен кондиционер куеп була. Тик менә урамны суытам димә. Телибезме, теләмибезме, ай ландшафтына әйләнгән дөньяга да чыгасы, чүлне дә әйләнеп кайтасы булачак. Әлеге җәһәттән, ягъни җайлашу дигәндә, бәлки ком гарәпләре – бәдәвиләр тормыш-көнкүрешен, алар яшәү рәвешен өйрәнә башлар вакыттыр? Тик шунысы билгеле: бәдәвинең бар булган мал-мөлкәте – бер дөя күтәрерлек йөк. Чатыр-торак та шунда, йорт кирәк-ярагы да, кием дә, ризык та. Барханнар арасында ихтимал автомобильнең кирәге калмас, барын шул хайванга төясе, шуңа атланып йөрисе булыр. Бүгенге заманның комфортка ияләшкән нәфесле кешесенә моның ишене күз алдына китерү авыр, тик язмыш белән килешкәнбез икән, белешә башлау, өйрәнә, күнегә тору зыянга булмас.

ҮСЕШ ЮЛЫНДА

tatarstan.ru

Киләсе елдан илдә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме артачак. Ә Татарстанда Олимпия чемпионы Алинә Заһитова мәктәбен ачарга ниятлиләр. Бу көннәрдә Төньяк башкалада узучы Петербург халыкара икътисадый форумы әнә шундый яңалыклар алып килде.

Серне чиштеләр

Белгечләр әйтүенчә, Санкт-Петербургта узучы икътисадый форум – дөнья күләмендә иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе. Ул 1997 елдан бирле, пандемия чорыннан кала, ел саен уза. Җомга көнне форумның пленар утырышында Россия Президенты Владимир Путин да катнашты. 1 сәгать тә 22 минут дәвам иткән чыгышы барышында ул бүгенге катлаулы шартларда илнең үсеше турында сөйләде. Бу – аның әлеге форумда ясаган чыгышларыннан иң озыны.

Без – икенче! Россия төбәкләрендә инвестицион климат торышы илкүләм рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Мәскәүгә генә уздырган. Исемлекне икътисадый форум кысасында игълан иттеләр. Исегезгә төшерәбез: илкүләм рейтинг төбәк хакимиятләренең бизнес өчен уңай шартлар тудыруын бәяли һәм моңа бәйле иң яхшы тәҗрибәләрне ачыклый. Узган ел нәтиҗәләре буенча нибары ике төбәк – Мәскәү һәм Татарстан 300 баллык чикне узып киткән. Россия Хөкүмәте Рәисе беренче урынбасары Андрей Белоусов республиканың инде бишенче тапкыр 2 нче урынга лаек булуын да билгеләп үтте.

Җыенда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов алдынгылыкның серен дә чиште.

– Беренчедән, без кече һәм урта бизнес өчен яхшы инфраструктура булдырдык. Сәнәгать мәйданчыклары гамәлдә. Анда 97 мең кеше эшли, 596 миллиард сумлык продукция төяп озатылган. Икенчедән, кадрлар әзерләү буенча эш алып барабыз. Ресурс үзәкләре булдыру юнәлешендә җитди эшлибез, бүген республикада шундый 45 үзәк бар. Өченчедән, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүдә ярдәм күрсәтәбез. Республика маркетинг үзәген булдырдык, анда 4400 катнашучы бар, алар 196 миллиард сумлык заказ алды инде, – дип сөйләде Рөстәм Миңнеханов.

Чит илләр түгел

Татарстан белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләре арасында товар әйләнеше арта. Бу хакта Рөстәм Миңнеханов әлеге илнең икътисад министры Абдулла бән Тук Әл Марри белән очрашканда әйтте. 2022 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләре арасында товар әйләнеше 71 миллион доллар тәшкил иткән. Яклар быелның май аенда узган «KazanForum» турында да фикер алышты. Хәтерләсәгез, Татарстан башкаласында узган икътисадый җыенга Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән зур делегация килде. Рөстәм Миңнеханов чит ил делегациясен «KazanForum – 2024»тә катнашырга да чакырды.

Мисыр Гарәп Республикасының сәүдә һәм сәнәгать министры Әхмәд Самир белән очрашу бырышында Рөстәм Миңнеханов чит ил кунагын Татарстанга чакырды. Форум мәйданында Татарстан Рәисе Үзбәкстан вице-премьеры Җәмшид Хоҗаев белән дә очрашты.

Заһитова мәктәбе

Петербург халыкара икътисадый форумы кысасында, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Россия Финанс министрлыгының контроль-ревизия органнарына 100 ел: киләчәк турында диалог» сессиясендә катнашты. Сөйләшү барышында Рәис алып баручының сорауларына җавап бирде. Шул исәптән бюджет акчасын максатчан һәм нәтиҗәле куллану турында да фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов соңгы елларда республикада финанс чараларын тәртипкә китерү юнәлешендә җитди эш алып барылуына игътибар итте.

– Бюджетны саклап калу өчен без контроль системасының эшен тәгаенләштерергә тиеш. Үз вакытында республикада дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы төзелде. Без даими рәвештә башкарылган эшкә йомгак ясап барабыз, бу игътибар таләп итә торган мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итә. Без тәртип яклы, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Форум кысасында Татарстан төрле юнәлештәге килешүләр имзалады. Шул исәптән Россия Хөкүмәте урынбасары Дмитрий Чернышенко һәм Рөстәм Миңнеханов киләсе елда Казанда узачак «Киләчәк уеннары» буенча килешүләргә кул кую тантанасында да катнаштылар.

Икътисадый форумда спорт турында да сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов Олимпия чемпионы Алинә Заһитова белән очрашты. Сәбәбе дә бар: Татарстанда Алинә Заһитованың фигуралы шуу мәктәбен ачу проекты турында фикер алыштылар.

– Сез – яшьләр өчен яхшы үрнәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Республикада төрле юнәлешләр буенча спорт мәктәпләре булдыру тәҗрибәсе бар инде. Без аны спортның башка төрләре, шул исәптән фигуралы шууда да файдаланырга әзер.

Эльвира ВӘЛИЕВА

РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ВЛАДИМИР ПУТИН ӘЙТКӘН ТӨП ФИКЕРЛӘР

☑ 2022 ел Россиянең хәзерге тарихында иң катлаулы чор булды. Без моңарчы күрелмәгән санкцияләр белән очраштык. Бүген шуны ышандырып әйтергә мөмкин: ул вакытта сайлаган стратегия дөреслеген раслады.

☑ 2023 ел нәтиҗәләре буенча илнең эчке тулай продукты үсеше 1,5–2 процент тәшкил итәчәк. Россиядә инфляция дәрәҗәсе күп кенә Көнбатыш илләренә караганда да түбәнрәк. Ул тарихи минимумга якын һәм 2,9 процентка тиң.

☑ Дәүләтнең финанс мөмкинлекләре социаль тигезсезлек һәм ярлылык күрсәткечләрен киметү юнәлешендә эшләү мөмкинлеген бирә. 2022 елда илдә 1,7 миллион кеше фәкыйрьлек чигеннән чыкты. Халыкның реаль кереме үсә башлады.

☑ Чит ил компанияләренең китүе Россия бизнесына яңа мөмкинлекләр ачты. Бизнес вәкилләре читтә «адашып» йөрүчеләрне кире кертмәскә тәкъдим итә. Әмма Россия көндәшлектән курыкмый. Чит ил җитештерүчеләре кире кайтырга тели икән, безнең ишекләр һәрвакыт ачык. Әмма аларның үз-үзен тотышы исәпкә алыначак.

☑ 2030 елга кадәр илдәге 100дән алып 500 кешегә кадәр кеше яшәүче торак пунктларны сыйфатлы элемтә һәм интернет белән тәэмин итеп бетерергә кирәк.

☑ Былтыр товар экспорты рекордны яңартты һәм 592 миллиард доллар тәшкил итте. Без чит илдәге җаваплы хезмәттәшләребез белән элемтәләрне эзлекле рәвештә ныгытуны дәвам иттерәчәкбез.

☑ Узган ел илдә 20 мең чакрым юл төзекләндерелде. Бу – рекордлы сан.

☑ 2022 елда эчке туризм 16,7 процентка үсеп, 10 миллион кеше тәшкил итте.

☑ 2024 елның 1 гыйнварыннан хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 18,5 процентка артачак.

☑ 1,5 яшькә кадәр бала тәрбияләгән өчен билгеләнгән пособиене, гаиләнең кереме үзгәрүгә карамастан, закон нигезендә акчаны алырга мөмкин булган вакыт беткәнче түләргә тәкъдим итәм. Югыйсә пособие алучы гаиләләргә яхшырак түләнә торган эш эзләү отышсыз булып чыга. Болай булырга тиеш түгел. Инвалид бала тәрбияләүчеләргә исә өлешчә мәшгуль булган очракта да, пособие түләргә кирәк. Моның өчен «өлешчә мәшгульлек» атамасы якын арада ук канун белән билгеләнәчәк.

☑ Россиядә эшлекле мохит мөмкин кадәр ирекле булырга тиеш. Былтыр илдә бизнеска бәйле 339 мең тикшерү үткәрелгән, ковидлы 2020 ел белән чагыштырганда бу 20 процентка кимрәк. Кешегә зур зыян салу куркынычы янамаган бизнесны, гомумән дә, тикшерүләрдән азат итәргә кирәк дип саныйм.

☑ Илдә ясалма интеллект, йөртүчесез «КамАЗ»лар, робот техникасы юнәлешләрен үстерергә һәм массакүләм кулланышка кертергә кирәк.

☑ Ел ахырында инфляция 5 процент дәрәҗәсендә булырга мөмкин.

☑ Россия – «цифрлы дәүләт» өлкәсендә дөньякүләм лидерларның берсе. Без суверенитетка ирештек.

БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР

«ДИНАМО» СПОРТ УЕННАРЫНА ИКЕ МЕҢ СПОРТЧЫ ҖЫЕЛДЫ

Казанга җиңәр өчен килдек! Тәүге тапкыр уздырыла торган «Динамо» спорт уеннарында катнашучыларның сүзләре бу. Татарстан башкаласында зур спорт бәйрәме 21 июньгә кадәр гөрләячәк. Без исә аның ачылыш тантанасында булып, Россиянең һәм якын чит илләрнең иң көчле спортчылары белән аралашып кайттык.



«Татар-информ»

Гомерле булсын!

100 еллык тарихы булган «Динамо» җәмгыяте оешмалары Россия төбәкләрендә генә түгел, якын-тирәдә урнашкан чит илләрдә дә эшли. Казанга Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстан һәм Белоруссиядән дә спортчылар килде. «Динамо» Бөтенроссия физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисе Анатолий Гулевский да әлеге спорт бәйрәменең географиясе шактый киң булуын искәртте.

– Спортчылар бу көннәрдә чын мәгънәсендә иң яхшы спорт корылмаларында көч сынашачак. Мин сезгә бары уңышлар гына телим! – диде ул.

Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе, Татарстанның «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте советы рәисе Әсгать Сәфәров фикеренчә, «Динамо» – массакүләм спорт, патриотик тәрбия кебек мөһим өлкәләрдә бик зур нәтиҗәләр күрсәткән зур берләшмә.

– Татарстанны күпләр Россиянең иң көчле спорт төбәге буларак таный, ә Казан илнең спорт башкаласы булып санала. Бездә «Динамо»га караучы 26 коллектив эшли, 30 меңләп спортчыбыз һәм 21 Олимпия чемпионыбыз бар. Без үзебездә әледән-әле дөнья күләмендәге мәртәбәле чараларны кабул итүебез белән бик горурланабыз. Бу уеннар дәвамлы булыр дип ышанам, – диде Әсгать Сәфәров.

«Казанга гашыйк булдык!»

Халыкара класслы спорт остасы Сарбон Ерназаров Үзбәкстан командасы өчен чыгыш ясый. Дөньякүләм спорт ярышларында бик күп тапкырлар чыгыш ясаганы булса да, «Динамо» спорт уеннарында катнашуы белән аеруча горурлана ул.

– Моннан 20 ел элек спортта тәүге адымнарымны «Динамо»да ясадым. Ул чакта да, хәзер дә бу җәмгыять сыйфатлы спорт өлгесе булып тора. Аның бер гасырлык юбилее уңаеннан уздырылган ярышларда катнашуыма чиксез шат мин, – диде самбочы Сарбон. – Казанга төгәл 10 ел элек Универсиадага килгән идем. Ул чакта шәһәр таң калдырды, һәм мин үземне Олимпиадада кебек хис иттем. Оештыру шул дәрәҗәдә яхшы иде чөнки. Быел да аннан ким түгел.

Белоруссиядән килгән Юрий Каптеров – җиңел атлетика буенча спорт остасы. 35 яшьлек МЧС хезмәткәре ярышларда беренче булырга өметләнә.

– Инде шактый еллар спорт карьерам «Динамо»га бәйле. Монда килеп, төрле илләрнең динамочылары белән очрашуыма бик шат. Россиядә күп тапкыр булганым бар, ә Казанга беренче килүем. Шәһәр, аеруча сездәге спорт корылмалары шаккатырды. Спортчыларыгыз өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган икән, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Билгеле, үзебезнең спортчыларга да уңышлар теләргә онытмадык.

– Мондый ярышта Татарстан исеменнән чыгыш ясау куркыта да, шул ук вакытта горурлык та өсти. Нәтиҗәсе яхшы булыр дип өметләнәм, – диде 23 яшьлек Фазыл Хөсәенов.

Спортчылар ниндидер акчалата призлар өчен түгел, ә махсус кубоклар өчен көч сынаша. Бу турыда «Динамо» спорт уеннарына багышланган матбугат очрашуында ук хәбәр иткәннәр иде. Ә спортчылар ярышудан бигрәк, бергә җыелганнарына сөенә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БЕЛГӘННЕ САНАР ЧАК



Татар теленнән БРИ тапшырган 8 укучының берсе – Ихтыяр Кыямов.

Ниһаять, рус теле һәм математикадан БДИ нәтиҗәләре билгеле булды. Математикадан республикада уртача балл – 62,52, рус теленнән – 72,01. Кемнәр көчлерәк: гуманитарийлармы, әллә техникларммы? Имтиханнарның төп этабы 1 июльгә кадәр дәвам итәчәк.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, профильле математикадан сынауны 7479 укучы сайлаган. Уртача балл бераз кимрәк. Быел ул – 62,52, былтыр әлеге күрсәткеч 64,06 булган. Быел 100 балл туплаучылар да күпкә азрак. Узган ел «акыллы баш»лар 18 булса, быел – 4. Минималь бусаганы 298е, ягъни 3,99 проценты үтә алмаган. Математикадан база өлешен сайлаучы укучылар – 7290. Билгеле булганча, математикадан база сынавын биреп, вузга профильле юнәлешләргә укырга кереп булмый. Бу фәннән уртача билге – 4,32. 74 укучы биремнәрне чишә алмаган.

Рус теленнән БДИны 14790 укучы тапшырган. Бу узган ел белән чагыштырганда 900 кешегә кимрәк. Уртача баллар былтыргыдан әллә ни аерылмый. Быел ул – 72,01, былтыр әлеге күрсәткеч 72,8 булган. 54 егет-кыз 100 балл җыйган. 2022 елда андыйлар – 88. Минималь бусаганы (24 балл) 12 укучы үтә алмаган. Сигез укучы җитди сәбәпләр аркасында сынауга килә алмаган, алар имтиханны башка көнне тапшырачак. Бер укучы кагыйдәләрне бозган өчен имтиханнан чыгарылган.

– Кызыбыз математиканы – «4ле»гә, рус телен 69 баллга бирде. Сыйныфта рус телен бик аз баллга язганнар. Димәк, безнеке булдырган, – дип сөенече белән уртаклашты Казанда яшәүче Гөлнур Әмирова.

Мәҗбүри фәннәрдән минималь бусаганы үтә алмаган укучылар 22 июньдә – рус теленнән, 26 июньдә математикадан кабат үз белемнәрен сынап карый ала. Нәтиҗә белән килешмәүчеләр апелляциягә гаризалар тапшырырга мөмкин.

Химия, география һәм рус әдәбияты буенча имтихан нәтиҗәләрен әле узган атнада ук җиткерделәр. Икесе буенча күрсәткечләр узган елгыдан яхшырак. Татарстан укучылары химияне 66,74 (былтыр – 61,71), рус әдәбиятын 72,67 (64,86) баллга тапшырганнар. География буенча уртача күрсәткеч узган ел 62,43 балл булса, быел аны 62,41гә тапшырганнар. Химиядән – 26, географиядән – 2, рус әдәбиятыннан 65 укучы 100 балл җыйган.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 8 июнендә кабул ителде

1 статья

2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 452 715 259,1 мең сум һәм чыгымнар буенча 463 181 407,9 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 10 466 148,8 мең сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләре белән расларга:

1) әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

2) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

3) әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

4) әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 13 июнь, № 42-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

2022 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 8 июнендә кабул ителде

1 статья

2022 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 64 768 498,8 мең сум һәм чыгымнар буенча 64 230 596,7 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артып киткән күләмен 537 902,1 мең сум итеп, түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары буенча әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре буенча әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

3) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары структурасы буенча әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 13 июнь, № 43-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Конституция советы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 8 июнендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституция советының статусын, вәкаләтләрен, аны оештыру нигезләрен һәм эшчәнлеге максатларын, составын һәм аны оештыру тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларының статусын билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасы Конституция советы статусы**

1. Татарстан Республикасы Конституция советы (алга таба – Конституция советы) «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 7-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә төзелә һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында гамәлгә ашыра торган даими эшләүче Татарстан Республикасы дәүләт органы булып тора.

2. Конституция советының эшчәнлек тәртибе, шул исәптән Конституция советы актларын кабул итү сроклары, федераль законнар, әлеге Закон һәм башка Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Конституция советы Регламенты (алга таба – Конституция советы Регламенты) белән билгеләнә. Конституция советы эшчәнлегенең төп рәвеше утырышлардан гыйбарәт, аларда аның вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр хәл ителә.

3. Конституция советы юридик зат булып тора, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән һәм үз исеме төшерелгән мөһергә һәм бланкларга ия була.

3 статья. **Конституция советы эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Конституция советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, бүтән Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

4 статья. **Конституция советының эшчәнлек принциплары**

Конституция советы эшчәнлеге законлылык, объективлык, оештыру мөстәкыйльлеге, функциональ бәйсезлек, коллегиальлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

5 статья. **Конституция советы вәкаләтләре**

1. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары мөрәҗәгате буенча түбәндәгеләрнең конституциячеллеге яисә конституциячел булмавы турында бәяләмәләр чыгара:

1) Татарстан Республикасы законнарының яисә аларның аерым нигезләмәләренең;

2) Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларының;

3) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының.

2. Конституция советы Татарстан Республикасы законнары яисә аларның аерым нигезләмәләре, Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән үз хокуклары бозылган дип санаучы гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре буенча әлеге норматив хокукый актларның конституциячеллеге яисә конституциячел булмавы турында бәяләмәләр чыгара.

3. Конституция советы Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелгән законнар проектлары (алга таба – Татарстан Республикасы законы проекты) буенча бәяләмәләр чыгара.

4. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә аңлатма бирә.

5. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы исеменнән Россия Федерациясе субъектлары белән төзелә торган шартнамәләр (килешүләр) проектларының (алга таба – Татарстан Республикасы шартнамәсе проекты) Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турында үз фикерен белдерә.

6. Конституция советы Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

7. Конституция советы Татарстан Республикасы конституциячел законлылык үсешен фәнни-методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

8. Конституция советы Татарстан Республикасы халкын хокукый агартуга, анда хокукый культураны булдыруга һәм үстерүгә ярдәм итә.

9. Конституция советы гражданнар мөрәҗәгатьләрен федераль законда билгеләнгән тәртиптә карый.

10. Конституция советы Конституция советы Регламентын, Татарстан Республикасы Конституция советы аппараты турында нигезләмәне раслый.

6 статья. **Конституция советы составы һәм аны төзү тәртибе**

1. Конституция советы, Конституция советы Рәисен дә кертеп, өч Конституция советы әгъзасыннан тора.

2. Конституция советы әгъзалары вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән билгеләп куела.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Конституция советы әгъзаларына бер кандидатны Татарстан Республикасы Рәисе, ике кандидатны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә.

4. Конституция советы әгъзасын вазыйфага билгеләп кую индивидуаль тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

5. Конституция советы Рәисе вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләп куйган Конституция советы әгъзалары арасыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдиме белән билгеләп куела.

6. Конституция советы, составында кимендә ике Конституция советы әгъзасы булганда, үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга хокуклы.

7. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре туктатылган очракта вакантлы урынга башка затны билгеләп кую турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә тиешенчә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кертелә.

7 статья. **Конституция советы әгъзасына кандидатка карата куела торган таләпләр**

«Юриспруденция» белгечлеге буенча югары юридик белеме яисә «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча бакалавр дипломы булганда «магистр» квалификацияле (дәрәҗәле) «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча югары белеме булган, юриспруденция өлкәсендә кимендә 10 ел эш стажы булган, хөкем ителүе булмаган яисә хөкем ителмәгән йә аңа карата җинаять эзәрлекләве реабилитация нигезендә туктатылган, 35 яшьтән яшьрәк булмаган Россия Федерациясе гражданы Конституция советы әгъзасы була ала.

8 статья. **Конституция советы әгъзасы статусы**

1. Конституция советы әгъзалары Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын били һәм үз вәкаләтләрен профессиональ даими нигездә башкара.

2. Конституция советы әгъзасы үз статусына туры килми торган эшчәнлекне вазыйфага билгеләнеп куелган көннән башлап 14 календарь көн эчендә туктатырга тиеш.

3. Конституция советы әгъзалары вазыйфага биш елга билгеләнеп куела. Бер үк зат Конституция советы әгъзасы итеп ике сроктан артыкка билгеләнеп куела алмый.

4. Конституция советы әгъзаларына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә бәйле Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар тарала.

9 статья. **Конституция советы Рәисе**

1. Конституция советы Рәисе:

1) Конституция советы утырышларын әзерләүгә җитәкчелек итә, аларны чакыра һәм аларга рәислек итә;

2) Конституция советына аның утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләрне фикер алышуга кертә;

3) дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар белән үзара эшчәнлектә Конституция советын тәкъдим итә;

4) Конституция советы аппаратына гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

5) әлеге Закон һәм Конституция советы Регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

2. Конституция советы Рәисе үз вәкаләтләрен башкара алмаган очракта аның вәкаләтләрен вакытлыча башкару тәртибе Конституция советы Регламенты белән билгеләнә.

10 статья. **Конституция советы әгъзасы вәкаләтләрен туктату**

1. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вәкаләтләрен туктату өчен каралган нигезләр буенча туктатыла.

2. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән туктатыла.

3. Конституция советы Рәисе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кертелә. Конституция советының башка әгъзалары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Конституция советы Рәисе тарафыннан кертелә.

11 статья. **Конституция советы актлары**

1. Конституция советы әлеге Законның 5 статьясындагы 1 – 3 һәм 5 өлешләрендә саналган мәсьәләләр буенча бәяләмәләр, ә әлеге Законның 5 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән мәсьәлә буенча аңлатмалар кабул итә.

2. Конституция советы бәяләмәләре Конституция советы тарафыннан тикшерелгән материалларга нигезләнгән булырга тиеш. Бәяләмә чыгарганда Конституция советы карала торган норматив хокукый актның, Татарстан Республикасы законы проектының, Татарстан Республикасы шартнамәсе проектының турыдан-туры мәгънәсен бәяли. Норматив хокукый актны караганда Конституция советы аңа рәсми һәм башка аңлатмада яисә гамәлдәге хокук куллану тәҗрибәсендә бирелә торган мәгънәне дә бәяли. Конституция советы бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәлә буенча гына, ә норматив хокукый актны караганда аның мөрәҗәгатьтә конституциячеллегенә шик белдерелгән өлешенә карата гына бәяләмә чыгара. Бәяләмә чыгарганда Конституция советы мөрәҗәгатьтә бәян ителгән нигезләүләргә һәм дәлилләүләргә бәйле түгел.

3. Конституция советы бәяләмәдә Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актының яки аларның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы законы проектының, Татарстан Республикасы шартнамәсе проектының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе яисә туры килмәве турында фикерләрен бәян итә.

4. Бәяләмә, аңлатма Конституция советы тарафыннан ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителә. Конституция советының кимендә ике әгъзасы яклап тавыш биргән очракта Конституция советы бәяләмәсе, аңлатмасы кабул ителгән дип санала. Конституция советы әгъзаларының берәрсенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә ул сәламәтлегенә яки вәкаләтләрне башкаруга вакытлыча комачаулык итә торган башка хәлләргә бәйле рәвештә вакытлыча булмаган очракта, бәяләмә, аңлатма кабул иткәндә Конституция советы әгъзалары тавышы тигез бүленсә, Конституция советы Рәисе яисә Конституция советы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы тавышы хәлиткеч була.

5. Конституция советы бәяләмәсе чыгарылган көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча Конституция советы бәяләмәсе кагыла торган Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга җибәрелә.

6. Әлеге Законның 5 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә саналган мәсьәләләр буенча чыгарылган Конституция советы бәяләмәсе, Конституция советы аңлатмасы «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында басылып чыгарга, «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Конституция советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актын йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныган яки хокукый җайга салудагы өзеклекне юкка чыгару таләбе булган Конституция советы бәяләмәсе әлеге норматив хокукый актны чыгарган орган (вазыйфаи зат) тарафыннан Конституция советы бәяләмәсе басылып чыкканнан соң өч айдан да соңга калмыйча мәҗбүри каралырга тиеш.

12 статья. **Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турында доклад**

Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына елга бер тапкыр Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турында доклад юллый. Доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Конституция советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.

13 статья. **Конституция советы аппараты**

1. Конституция советы эшчәнлеген Конституция советы аппараты тәэмин итә.

2. Конституция советы үзенең чыгымнар сметасы кысаларында Конституция советы аппараты структурасын һәм штат расписаниесен билгели.

3. Конституция советы аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре булып тора.

4. Конституция советы эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү максатларында Конституция советы аппараты штат расписаниесенә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән вазыйфалар өстәлергә мөмкин.

14 статья. **Конституция советы эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү**

1. Конституция советы эшчәнлеге финанс белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тәэмин ителә.

2. Конституция советын финанслау чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында законда аерым статья белән карала.

15 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 13 июнь, № 44-ТРЗ

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 8 июнендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда «29^3 статьяның 2 һәм 3 пунктларының («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 36 – 38 өлешләре нигезендә бирелә торган махсус казна кредитларына карата),» сүзләрен «29^3 статьяның 2 һәм 3 пунктларының («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук – Федераль закон) 9 статьясындагы 36 – 38 өлешләре нигезендә бирелә торган махсус казна кредитларына һәм бердәй бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга Федераль законның 9 статьясындагы 41 өлеше нигезендә бирелә торган бюджет кредитларына карата),» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) 2 өлештә «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләреннән соң «, бердәй бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга Федераль законның 9 статьясындагы 41 өлеше нигезендә бирелә торган бюджет кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләреннән соң «, бердәй бюджет счетында калган акчаларны тулыландыруга Федераль законның 9 статьясындагы 41 өлеше нигезендә бирелә торган бюджет кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлештә «башка максатларга бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта,» сүзләреннән соң «Федераль законның 9 статьясындагы 36 һәм 41 өлешләрендә күрсәтелгән бюджет кредитлары бирелгән очракта,» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 13 июнь, № 45-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башлыгы **Николаева** Тамара Сергеевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыятенең күмәч цехы камыр куючысы **Гайсина** Алсу Тәлгать кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эрен хирургиясе бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Әсәдов** Чыңгыз Фәрхәд улына, «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Головкина** Фәнүзә Шамил кызына, «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Сафиуллина** Гөлнара Илдус кызына, «Актаныш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы (гаилә табибы) **Трегулова** Кадрия Әнис кызына, «Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Әлмәт туберкулезны дәвалау диспансеры» филиалы баш табибы **Усманов** Ринат Илгизәр улына, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника бүлекчәсе табибы – стоматолог-терапевты **Фәттахов** Дамир Мөнип улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «М.П.Прокопьев исемендәге Нырья урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучысы **Жуков** Владимир Туймурзовичка, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Лельвиж урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Капитонов** Евгений Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрне саклауга һәм үстерүгә, милләтләр арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытуга өлеш кертүе өчен Балтач муниципаль районының «Балтач үзәкләштерелгән авыл клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 42 номерлы филиалы мөдире **Сапожников** Леонид Дмитриевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сабантуй

Сабантуймы, Сабантуй –
Уеннар туе бит ул,
Тәм-томнар сые бит ул,
Җыңүләр уе бит ул.

Чаптар өстендә чабып,
Катыктан тәңкә табып,
Колга башына менеп,
Узышлыга йөгереп

Һәм татарча көрәшеп,
Аркан белән сөйрәшеп,
Ватмый йомырка ташып,
Тапкырлыкта сынашып

Җиңсәң әгәр,
Сабантуй –
Эчкә шатлык
сыймас туй!

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Нәфисә мар, Әнисә

Бервакыт, Мими дип аталган чуаш авылына барып чыккач, шундагы мәктәптә эшләүче өлкән яшьтәге әдәбият укытучысы белән таныштым. Ул, минем татар икәнемне белгәч, мондый сорау биреп куйды:

– Сездә Әнисәне укыйлармы, Бәширинекен? Аны студент чагымда ук укыганым бар иде, һаман истә тора, әйбәт язучы ул сезнең…

Бәшири дигәч, ул, ялгышып, Гомәр Бәширне һәм «Намус» романының баш герое Нәфисәне күз уңында тотмыймы икән, дип уйлап алдым. Шуңа күрә:

– Бәширнең Нәфисәсен, ягъни «Намус» романын әйтүегезме? – дип сорадым.

– Юк, юк! Бәширинең «Чуаш кызы Әнисә» дигән әсәре! Революциягә хәтле үк иҗат иткән ул аны! – дип ачыклады әңгәмәдәшем. Һәм чуашча өстәп куйды. – Нафиса мар, Аниса.

Мин берничек тә җавап бирә алмадым. Чөнки Бәшири исемле язучыны белмим һәм аның чуаш авылы укытучысы әйткән әсәрен дә укыганым юк иде. Турысын әйтим, оятка калдым мин шул чакта Мими авылында.

Баксаң, Зариф Бәшири – ачылмаган утрау икән. Китапханәләрдән, китап кибетләреннән эзләп карадым мин аның китапларын, әмма бер генә басмасын да таба алмадым. Нәшрият яисә институт архивларына кереп эзләнгәнем булмады. Шуңа күрә чуаш мөгаллиме әйткән әлеге әсәрне 2014 елда гына укый алдым. Зариф Бәширинең сайланма әсәрләре Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде ул елны. Язучының иҗатын ачыш кебек кабул иттем дип әйтәсем килә. Һәм, әлбәттә, аның язмышы белән кызыксынуым да көчле булды. 1888 елда туган Зарифның шигырьләре узган гасыр башында ук күренә башлаган. Совет чоры төрмә-лагерьларында озак еллар иза чиккән әдипнең истәлекләре дә гаять кызыклы һәм әһәмиятле. Кемнәр белән генә эшләргә һәм танышырга-аралашырга насыйп булмый аңа! Тукай, Гафури, Дәрдмәнд, Рәми, Бабич, Галимҗан Ибраһимов… Мондый атаклы шәхесләр белән күрешеп яшәүне язмыш бүләге дип тә әйтергә ярыйдыр, минемчә.

Бүгенге татар укучысы беләме икән соң Зариф Бәширине? Бу сорауны минем китапханәләргә яисә мәктәпләргә кергәч, шунда эшләүчеләргә турыдан-туры биргәнем бар. Командировкаларда районнарда йөргәндә дә кызыксынмый калмыйм. Ни кызганыч, белүче кешене очратканым булмады. Бервакыт өлкәнрәк яшьтәге бер укытучы: «Тыелган язучы дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар», – дип кенә әйтә алды. Ә инде яшьрәкләр татар язучысының шушы бер китабы чыгуын гына әйтте. Аны да, әлбәттә, җәһәт кенә интернетта эзләп табып «исләренә төшерделәр». Шулай булгач, аларга китапның эчтәлегенә кагылышлы сорау бирүдә мәгънә юктыр дип уйлыйм.

Китапны төзүче Ркаил Зәйдулла болай дип язган: «…Без бу юлы чәчмә әсәрләрне генә сайладык, Зариф Бәширинең шигырьләрен туплап чыгару – киләчәк эше. Әдәби мирасыбыз онытылырга тиеш түгел… Аның иҗатын җентекләбрәк өйрәнергә вакыттыр, мөгаен. Ул чакта татар әдәбиятының тарихы да яңа яклары белән ачылып китәр иде…»

Без көтәбез инде. 2014 елдан бирле көтәбез. Әмма әдәбият сөючеләрне куандырырлык яңалык күренми әле.

Без генәме соң? Әнә күршеләребез дә кызыксына икән бит Зариф Бәшири исемле татар язучысы белән!

Ильяс САЛИХҖАН

КҮРКӘМ КҮЛМӘК

Мәктәп капкасына җиткәнче утызлап хатын-кызга игътибар иттем. Менә бусагада оныгымның класс җитәкчесе Ләйлә күренде. Күлмәктән! Башка вакытта җилкәсенә тараткан озын чәчен җыеп, баш артына төйнәп куйган. Әдәпле, тыйнак. Киң үкчәле аяк киеме дә килешле, дәрес барышында да, залда йөргәндә дә тавыш чыгармый. Барлык укытучылар да безнең Ләйлә кебек игътибарлы, сөйкемле, ягымлы булса иде ул, дигән теләк уянды. Саф татарча сөйләшүе үзе генә дә хөрмәтне бермә-бер арттыра! Әти-әни, әби-бабайларның һәркайсына үз телендә эндәшүе, төгәл, кыска җаваплары, урынлы киңәшләре соклангыч. Баланың менә шушындый укытучыда белем, тәрбия алуына сөенми мөмкин түгел. Укучыларының: «Безнең Ләйлә Эльданизовна – иң яхшы укытучы!» яки «Мировая красавица», – диюләре бик урынлы лабаса. Һәм алар гомер буе беренче укытучысы, мәктәпнең йолдызы булган түземле, тырыш, таләпчән апаларының тавышын, үз-үзен тотышын, киемен күңелләрендә йөртәчәк, гүзәллеген сагынып сөйләячәк һәм аның әдәп кагыйдәләрен кабатлаячак. «Урыссудагы беренче башлангыч мәктәптә мине Ләйлә апа өйрәтте», – дип горурланып искә алачак!

Сүземне хатын-кызны күркәм күрсәтүче күлмәк турында дәвам итәсем килә. Әнә ничек матур, тыйнак һәм күз төшәрлек итеп күрсәтә күлмәк хатын-кызны. Яшьләргә бигрәк тә килешеп тора бит әле ул. Дөрес, эштә, юлда, машина йөрткәндә, бәрәңге чүпләгәндә чалбар уңайлы инде үзе. Әмма башка вакытларда күлмәк киюгә җитми инде!

Шулай да гомер буе кофта-итәк, оек киеп, хатын-кыз рәвешен саклаучы апа, әбиләр аз түгел ул. 43 ел сыер савучы булып эшләгән Фаягөлне беләм мин. Башыннан яулыгы төшмәде. Эшкә барганда – чуар-чәчәкле, өенә кайтуга ап-ак яулыгын чөеп бәйләр иде дә йә өендә, йә бакчада, йә маллар арасында болында кайнашыр иде. Һәм беркайчан да кара чалбар кимәде! Нинди генә хезмәттә булсаң да, көннәр буе компьютер каршында утырганда да, күлмәк яки итәк уңайлырак кебек тоела миңа. Бу фикерем күп еллар күңелемне борчый инде. Сыланып торган джинс белән үзен тилмерткән хатын-кызларга бик гаҗәпләнәм.

Җәй җитте. Чыгарыгыз матур аякларыгызны кояш яктысына, соклансын шагыйрьләр, тудырсыннар яңа шигырьләр, җиңеләйсен адымнарыгыз! Янәдән үзегезне хатын-кыз итеп тоеп шатланыгыз. Сау-сәламәт аяклар – гүзәллек бит ул.

ХАФИЗӘЛӘ.
Урыссу

ЭЛЕК САБАН ТУЕ НИЧЕК БУЛГАН?

Мәңге яшь һәм борынгы татар йоласы Сабан туе Яшел Үзән районы Айдар авылында июнь башларында, Кәвәлдә өч көнлек ярминкә белән Ака туй үткәрелгәч оештырыла торган иде.

1930 нчы елларга кадәр, «Игенче» колхозы оешканчы, Айдар авылында Сабан туе аеруча зур колач белән үткәрелгән. Күрше Күгеш, Әрә, Кармыш, Акъегет, Күгәй, Татар Исламы, Норлат һәм Тау Иле авылларыннан бик күп кунаклар чакырылган. Сабан туена бер көн кала, шушы авыллардан бизәлгән атлар белән кунаклар килеп төшкәннәр. Бәйрәм көнне һәр капка төбендә диярлек 3–5 ат торган. Ул вакытта Сабан туе берничә көн дәвам иткән.

«Игенче» колхозы оешкач, кунакларның атлар белән килүе бик нык кимегән, чөнки хуҗалыкларда атлар булмаган. Сабан туена әзерләнү берничә егетнең өйдән-өйгә йөреп бүләкләр – яулык җыюдан башлана. Яңа яшь киленнәр бүләккә чигүле сөлгеләр бирергә тиешләр иде. Бала-чагалар да тик ятмыйлар, алар бәйрәмгә йомырка җыялар. Үземә дә бу вакыйганың үзәгендә булырга туры килде. 1966 елны армия сафларына китәр алдыннан Кәлимуллин Фәрит, Зыятдинов Мансур, Шәйхуллин Равил белән Сабан туена яулыклар җыеп йөрдек. Бу елларда Сабан туе Күгеш авылында үткәрелә иде. Айдарда Сабан туе булырга ун көн кала авыл атларын чабыштыралар иде. Бу атлар аягын кыздыру дип атала.

Сабан туе атлар чабышыннан башлана. Атларны йә Күгәй юлыннан, йә Тау Иле юлыннан җибәрәләр иде. Колхозлашу чорына кадәр атлар саны 20–30га кадәр җиткән. Бу вакытта Сабир бабайның Алмачуар исемле аты беренчелекне бирмәгән. Ә без үскәндә Айдарның атаклы Алмаз исемле аты дан тотты.

Менә чабыш атлары килде, халык атлар янына йөгерә. Беренче килгән атны һәркемнең күреп, сөеп каласы килә. Иң кызыгы шул: иң арттан килгән ат янында да кешеләр күп, күбесе – әбиләр. Арттан килгән ат «нәзер аты» дип атала. Гомер-гомергә «нәзер аты» муенына сөлге, яулыкларны күбрәк бәйлиләр.

Ат чабышларыннан соң мәйданда көрәш башлана. Мәйдан Әркә күленнән өстәрәк урнашкан. Шуннан ерак түгел таган куелган иде.

Мәйдан тирәсендә төрле уеннар башкарыла: баганага үрмәләп менү, чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү, кузла өстендә капчык белән бәрешү һәм башкалар. Ул вакытларда мәйдан тирәли яшьләрнең гармуннар белән җырлап йөрүләре гадәти күренеш иде. Берничә түгәрәк эчендә яшьләр гармун көенә бииләр. Ә таганда атынырга – чират. Сабантуй көрәшчеләр арасында батырны билгеләгәнче бара иде. Ә кич яшьләр таган астына, кичке уенга җыелалар. Анда төне буе бииләр, җырлыйлар, таган атыналар иде.

Рәфхәт ФАЗЛЫЕВ

ЙОРТТА МӘХӘББӘТ ХУҖА

Әгерҗе районы Кырынды авылыннан Физәния белән Флүс Шамиловлар – гел игелекле гамәлләр кылып, кешеләргә ярдәм итеп, сөендереп, үзләре дә шуның әҗерен күреп, матур яшәүче үрнәк парларның берсе.

Алар гел бергә. Бер авылда туып-үсәләр, бер сыйныфта укыйлар. Флүс армия хезмәтендә чакта гына ике елга аерылып торалар.

– Армиягә озаттым да, көтеп тә алдым. Кайтышлый ук, өенә кергәнче, безнең капкага кагылды ул. Әнә шулай бер-беребезне яратып кавыштык та, бүгенгәчә мәхәббәт ялкынын һич киметмичә гомер кичерәбез. Өйдә мәхәббәт хуҗа булгач, бәхет касәбез гел тулы. Һәр иртәм сөекле иремнең аркамнан сөеп, битемнән үбеп, «Хәерле иртә!» дигән сүзеннән башлана, – дип балкып тора Физәния ханым.

Хәзер үзләре гаилә корып, икешәр бала үстерүче кызлары Фирзәнә, Гөлзинә, Илзидә дә: «Безне тату гаиләдә, ярату һәм кайгырту тоеп, кызым, дип кенә иркәләп үстерделәр. Әти-әни гаиләсе – безнең өчен матур үрнәк», – диләр.

Бәхетле парга матур гаилә төзү серләре яхшы таныш. Аларның беренчесе ярату булса, икенчесе – ике якның өлкәннәрен дә чын күңелдән олылау. Физәниянең әтисе, җиде баласын калдырып (иң олысына 15 яшь чакта), бакыйлыкка иртә күчкәнлектән, каенатасына авыз тутырып «әткәй» дип дәшә алуына сөенеп туя алмый яшь килен. Каенанасы белән дә бик тиз уртак тел таба. Яшьләр өй салып башка чыксалар да, өлкәннәр киленнәреннән һәрчак кадер-хөрмәт күреп яшиләр.

– Мич ашлары пешергәндә, үзебез ашаганчы, суынганчы дип, велосипедыма утырып, әткәй белән әнкәйгә илтә идем. Алар калдырган хәер-дога да бәхетле яшәтә

безне, – ди Физәния, тату гаиләнең тагын бер сере белән уртаклашып. Физәниянең әнисе дә, гомер буе кияве һәм кызының ярдәмен күреп, ихтирамын тоеп яши.

Гадәттә, өйнең нурлы, табынның мул булуы – хуҗабикәгә, каралты-кураның тәртиптә, абзардагы терлек-туарның сау булуы хуҗа кешегә бәйле. Шамиловларда нәкъ менә шулай.

– Бакчабыз зур. Андагы бөтен авыр эшне аты белән Флүс эшли. Күпләп үгезләр үстерәбез, аларны да үзе карый, – ди Физәния, җәмәгате белән горурланып.

Горурланырлыгы да бар. Хуҗалыктагы ат белән үзләренең генә түгел, авылдашларының да бакчаларын сөрә, бәрәңгеләрен өя һәм казып бирә, тирес тә түгә Флүс. Зиратны тәртиптә тотуга өлеш кертә, авылдашларны соңгы юлга озатудан да читтә калмый. Үзләреннән ерак түгел чишмәне дә, җиренә җиткереп, үзенә хас зур җаваплылык белән карап тора. Мал сую кебек җаваплы эштә дә күп авылдашларының уң кулы ул.

Физәния генә түгел, Флүс тә горурлана хәләл җефете белән:

– Физәния матурлыкны ярата. Йортыбыз тирәсе иртә яздан чәчәкләргә күмелә. Күңел җылысын биреп, җырлый-җырлый үстерә ул аларны. Мин белә-белгәннән бирле сәхнәдә булды, җыр-моң ярата. Ул – аш-су остасы, булдыклы хуҗабикә. Бик тырыш, һәрчак ачык йөзле, кунакчыл, кешелекле, ипле, тәртипле, ярдәмчел, – ди.

…Капка төбендәге матур кое янында, гөл-чәчәкләр арасында урын алган үз куллары белән ясаган пар аккош шушы гаиләнең символы булып тоелды. Тормыш дилбегәсен нык тотучы алтын куллы гаилә башлыгы Флүс һәм хатын-кызның бөтен асыл сыйфатларын үзенә туплаган хуҗабикә Физәниягә алтын, зөбәрҗәт, бриллиант туйларын да бергәләп бәйрәм итәргә язсын.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА

Ватанпәрвәр

Казанның Вахитов районында урнашкан Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат сарае шәһәребездә һәм республикабызда иң уңышлы эшләп килүче үзәк булып танылды. Мондый дәрәҗәгә ирешүдә 53 ел фидакарь хезмәт итүче, «Avante! Алга! Вперёд!» патриотик тәрбия бүлеге мөдире, халыкара конкурслар лауреаты Равилә Һадиеваның өлеше әйтеп бетергесез.

Бөек Ватан сугышында батырлыклар күрсәткән офицер кызы Равилә ватанпәрвәр булып үсә. Әнисе Рәкыйбә – тәҗрибәле педагог, дистә еллар шушы үзәкне җитәкли. Кыз әти-әнисеннән үрнәк алып үсә. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый да әнисе янына эшкә килә. Яраткан һөнәренә бар күңелен бирә. Республика мәктәп музейларына методик ярдәм күрсәтү, төбәкне өйрәнүчеләр арасында бәйгеләр оештыру, Абдулла Алиш музеен экспонатлар белән баету, яшь экскурсоводлар әзерләү өчен янып йөри. Һәр көне укытучы һәм укучылар белән аралашып, киңәш биреп, мәгънәле уза. Тырышканы юкка китми. «Халык мәгарифе отличнигы», «Татар мәгарифендә казанышлар өчен» мактау билгеләре, Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.

Равилә МӨБАРӘКШИНА

Мин – Ык буе баласы

(Парча)

Һәркемнең беренче кат дөньяга күзе ачылган, тирә-якның чиксез матурлыгын тоеп куанган туган ягы була. «Сез каян?» – дип сорасалар, мин горурланып: «Ык буйларыннан», – дип җавап бирәм.

Хозур елгам! Алга ургылып Иделгә таба юл алганда, нинди генә тарихи вакыйгаларның телсез шаһиты булмагансың син! Кайчандыр кесәсе калын байгуралар синең агышыңның юнәлешен үзгәртмәкче булып, чал Урал тавы буена тирән итеп канау казыганнар, әмма исәпләрендә ялгышканнар. Син авылыбыздан ераклашырга ашыкмагансың, сәяхәтеңне иске юлыңнан дәвам иткәнсең. Безнең төбәктәге Ямәлҗә явы турындагы риваятьләр дә, Миңгерә тауның текә кыясыннан тройка белән Ык төбенә сикергән алтын-көмешле патша кызы турындагы серле әкият тә синең белән бәйле, сихри елгам. Давыллы елларда гаепсезләрнең хәләл канын койган сәнәкчеләр фетнәсе вакыйгаларының да шаһиты син.

Инде халкыма күрсәткән игелекле эшләреңә игътибар итик. Болары инде бернинди үлчәүгә дә сыешлы түгел. Авыр сугыш елларын гына искә төшерик. Ачлыктан кая барып бәрелергә белмәгән тол аналар синең татлы тамырлы камышларың белән йөрәк ялгаганнар, витаминлы балтырганы, юасы, кузгалагы ярдәм иткән. Карама-чыбыкларың сугыш ятимнәренә җан өргән, өйләрне җылыткан. Юмарт әрәмәлекләреңдәге җиләк-җимешләр өстәлләрдә иң татлы сый-нигъмәт булып кешеләрне сөендергән. Көмеш суыңдагы алтын тәңкәле балыкларың иң ләззәтле ризык булып табынга куелган.

Гомер-гомергә гадәтемә кергән, каныма сеңгән, һәр сандугачлы язны мин ашкынып көтеп алам. Һәркемне үзеңә әйди торган тылсымлы ярларыңа төшәм дә беренче очраган көймәгә утырып йөзеп китәм. Шунда җаннарны хушландыра торган су өстенең саф җилен тоеп чиксез куанам. Ишкәгемне куям да көймәмне агым иркенә куеп йөзеп китәм. Газиз әнкәемнең йомшак бишеген хәтерләткән туган елгам, салмак дулкыннарында тибрәтеп, мине түбән таба алып китә. Менә шунда тынгысыз күңелне татлы бер сагыш биләп ала һәм балачак иленә сәяхәткә алып китә. Татлы хыялымнан мине фәкать тал-тирәккә кунып өздереп сайраучы сандугач моңы гына айнытып җибәрә.

Туган табигать! Мин сине елның теләсә кайсы фасылында бертөрле үк яратам. Язында тирә-юньгә хуш ис аңкыткан шомырт, балан, гөләп чәчәкләрен кемнең генә күрәсе килмәс тә, кемнең генә күңеле хушланганчы иснисе килмәс икән! Ә якты кояшлы җәй көннәрендә тәмле бал исе аңкыган, чәчәктән-чәчәккә күбәләкләр, бал кортлары сәяхәт иткән соклангыч мизгелләрдә су буйларыннан бер аваз салып узуы үзе бер гомер түгелмени?! Менә кайда ул Гадел Кутуй әйтмешли, илаһи матурлык, әйтеп бетергесез шагыйранә мәһабәтлек, җан рәхәте! Юкка гына халкым борын-борыннан ук, җыен-бәйге, мәйдан Сабан туйларын чәчәкле җәй аенда үткәрмәгән.

Ә алтын көз! Үзенә бер мавыктыргыч дөнья. Калган-поскан балан тәлгәшләренең әллә каян ымсындырып үз янына әйдәвен генә күр син! Көтеп алган «Әбиләр чуагы»нда бөрлегәнле сызаларны иңләргә яратам мин. Буыннарда рәхәт бер талчыгу сизә башлагач, ял итә торган ялгыз тал-тирәгемә сөяләм дә әйләнә-тирәне күзәтәм. Кызыксынган күңелем сызалардан калкулыкларга әйди. Үргә менәм һәм соклангыч манзарага хәйран калып туктап калам. Кояшның алтын нурларында җем-җем килеп җилфердәүче зелпе куагы пәйда була. Ул күз явын алырлык тоташ ал чәчәкне хәтерләтә. Тагы да арырак күз ташласаң, рәссам киндерендә генә була торган пейзаж-манзара игътибарыңны җәлеп итә. Нинди генә төсләр юк! Нәкъ салават күпердәге кебек усак кып-кызылдан киенгән, шомырт яфраклары саргаеп килә, ә тал-тирәкләр әле яшел киемнәрен салырга өлгермәгәннәр. Бу – рәсем генә түгел, табигатьнең үзе, үз хозурлыгы, үз чынбарлыгы. Гомәр Бәширов «Җидегән чишмә» романында: «Табигать ул – безнең туган өебез, тирбәлеп үскән җылы бишегебез. Табигатьтән башка кешелек җәмгыяте гомумән яши алмый», – дип яза.

Шулай булгач, без, Ык буе кешеләре, туган табигатьне, ямьле Ык буйларын ата-бабаларыбыздан ничек кабул итеп алган булсак, алдагы буыннарга, оныкларыбызга шундый ук гүзәллеге белән мирас итеп калдырырга бурычлыбыз.

Тәкыя ШӘРИПОВА

ТУРЫ ЮЛ

Яңадан туу белән бер. Төрмәдә утырып, иреккә чыккан кешенең яңа тормышка аяк басуын әнә шуның белән чагыштыралар. Республикадагы «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасы аларга туры юл күрсәтергә тырыша. Бер мәртәбә ялгышкан кеше кабат абынмасын өчен нишләргә? Үзәкнең генераль директоры Илнур САТДИНОВ белән шул хакта сөйләштек.

– Безнең төп максат – хөкем ителүчене акрынлап иреккә чыгарга әзерләү, тормышта аңа кабат үз урынын табарга ярдәм итү, яңадан кыек юлга кереп китүдән саклау. Үзәк ике юнәлештә эш алып бара. Без хәзерге вакытта төрмәдә утырган кешеләргә дә, иреккә чыкканнарына да ярдәм итәбез. Даими рәвештә колонияләргә барабыз, анда утыручылар белән күрешәбез. Аларга төрмәдән иртәрәк чыга алуларын аңлатабыз. Моның өчен тәртип бозмаска, эшләргә кирәклеген искәртәбез. Моңа риза булсалар, судка гарантия хаты тапшырабыз. Ник дигәндә, мәҗбүри эшләргә билгеләнер алдыннан алар иң элек судка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Бу йомшартылган җәза булып санала. Суд уңай карар чыгарса, хөкем ителүчене төзәтү үзәгенә күчерәләр. Без анда егетләрне каршы алабыз, эшкә урнаштырабыз, ашатабыз-эчертәбез. Эшкә бушлай алып барып, бушлай алып кайтып та куябыз. Төзәтү үзәгенә атнага бер тапкыр юрист, психолог килә. Анда Сабан туе кебек бәйрәмнәрне дә уздырабыз. Без аларга башка тормыш барын күрсәтәбез.

:: Төзәтү үзәгенең төп өстенлеге нидә?

– Монда инде хөкем срогын узу өчен бөтенләй башка шартлар тудырыла. Төзәтү үзәге аша иреккә чыккан кешегә гадәти тормышта үзенә урын табу күпкә җиңел булачак. Ник дигәндә, ул акрынлап иреккә ияләнә тора. Иртүк эшкә бара, кичен яңадан шул үзәккә әйләнеп кайта. Анда аларны автомат белән саклап торучы да, этләр дә юк. Алар үзләренә үзләре ашарга әзерли. Тәртипләре яхшы булса, ялларда шәһәргә дә чыгалар. Төрле оешмалар белән хезмәттәшлек итәбез. Егетләрне төрле эшләрдән башлап, төзелеш, авыл хуҗалыгы тармакларына эшкә урнаштырабыз. Без аларны иреккә чыккач кирәк булачак һөнәрләргә дә (ягулык салу станциясендә эшләүче, бетончы, тәрәзә куючы һ.б.) укытабыз.

:: Төрмәдән чыгучыларга да ярдәм итәбез, дидегез. Ул эш ничегрәк оештырылган?

– Төрмәдән чыккан кеше иң элек безнең приютка килә ала. Иреккә чыгу турында белешмәсе булса, без аңа азык-төлек җыелмасы, беренче вакытта кирәкле кием-салым бирәбез. Документларын торгызырга да ярдәм итәбез, фатир яллап, вакытлыча тору урыны белән тәэмин итәбез. Эшкә дә урнаштырабыз. Монда юрист, психолог та ярдәм күрсәтә. Иң мөһиме – хәмер белән мавыкмаска һәм эшләргә. Хәзерге вакытта без иреккә чыккан 230лап кешене яшәү һәм эш урыны белән тәэмин иттек. Төзәтү үзәгендә тагын 250ләп кешене эшкә урнаштырдык. Моннан тыш 400ләп кешенең документларын ясаттык.

:: Сезгә башка төбәкләрдән дә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләрме?

– Әйе, бигрәк тә Пермь, Пензадан мөрәҗәгать итүчеләр күп. Шушы тугыз ел вакыт эчендә без илнең төрлек төбәкләрендә яшәүче 15 меңләп хөкем ителгән кешегә ярдәм иттек.

:: Балалар белән дә очрашулар оештырасыз икән...

– Әйе, үсмерләр арасында җинаятьчелекне кисәтү өчен эшләнә бу. «Равный консультант» дип исемләнгән махсус программа нигезендә эшлибез. Әле күптән түгел генә Яшел Үзәндә тәртип ягы шактый аксаган үсмерләр белән очрашуда булдык. Балалар бар нәрсәне дә үзенчә аңлый бит. Полиция хезмәткәрләре, балигъ булмаганнар белән эшләүче инспекторлар күпме генә тукып торса да, аларның әйткәннәренә колак салмаска мөмкин. Ә без алар янына үзебез генә түгел – заманында үзе дә шушы кыек юлда булып, хәзер яңа тормыш башлаган кеше белән киләбез. Унбиш ел утырып чыккан кеше ул. Хәзер үзенең төзелеш бригадасы, хатыны, балалары бар, намазда. Очрашуда: «Мин дә сезнең кебек шук малай идем», – дип сөйли башлауга, малайларның йөзләре үзгәрә.

«Урам тормышы белән яшәдем, группировкага кереп киттем, җинаятьләр кылдым. Шуның аркасында унбиш ел гомерем рәшәткә артында узды. Гомеремнең иң матур чорын төрмәдә уздырдым. Иреккә чыктым – йортым да, гаиләм дә, саулыгым, хәтта авызымда тешем дә юк. Андый кеше кемгә кирәк? Тәртипсезлек беркайчан да яхшыга илтми. Шуңа күрә законны бозмагыз, белем алыгыз, эшкә урнашыгыз, гаилә корыгыз», – дип сөйли ул очрашу саен.

Малайлар шаккатып тыңлый, сораулар бирә. Кырын юлга кереп китүнең аяныччы нәтиҗәләрен әнә шундый чын язмышлар аша да аңлатырга кирәк.

:: Сезнең үзәк аша узып та, кабат җинаять юлына басучылар бармы?

– Шәхсән безнең үзәк аша иреккә чыккан егетләр арасында андыйлар бик аз. Булганнары да, нигездә, хәмер белән дус булучылар. Әйткәнемчә, безнең үзәктә инде алар ныгып, ирекгәге тормышка азмы-күпме әзерләнеп чыга. Шуңа монда чыккач «сынучылар» бик сирәк. Без бит аларның якыннары белән дә элемтәдә торабыз. Тулы канлы тормыш белән яшисе килсен өчен кешенең көтеп торучысы да булырга тиеш.

:: Киләчәккә планнарыгызны да ишетәсе килә.

– Безнең эшчәнлек башка төбәкләргә дә кызык. Шуңа бу тәҗрибәне башка төбәкләргә дә таратырга җыенабыз. Бер уйлап карасаң, мондый үзәкнең булуы дәүләткә дә отышлы. Төрмәдәге бер кеше өчен аена уртача 35 мең сум акча тотыла. Аны бит ашатырга, эчертергә, сакларга кирәк. Төзәтү үзәгендә алар үзләре ашарга әзерләп ашый, үзе акча эшли, кыскасы, үзләрен-үзләре тәэмин итә.

Әңгәмәдәш – Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Тирән тамырлар

Арча районында яшәүче Сәләховлар унике ел элек өйләрендә музей ачкан. Киштәләр экспонатлар белән шыплап тулган. Алар өчен аның саны мөһим түгел. Үткәннәрне искә төшереп уйлана торган урында ике якка да тигез игътибар бирелгән. Оныклар, балалар да буыннар бәйләнешен сизә монда.

Гөлзадә һәм Равил икесе бер сыйныфта белем алган. Казанбаш мәктәбен тәмамлаганнар. Чәчләре чәчкә бәйләнгәнгә – 41 ел. Икесе бертөрле уйларга, шул ук вакытта бер-берсен тулыландырырга ярата алар. Әгәр шулай булмаса, мондый музей туар идеме икән? «Нигә кирәк бу синең иске үтүгең, комганың, самавырың?.. Аны куярга башка урын беткәнмени?» – дип каршы төшәрләр иде. Ә бит алар җансыз әйберләргә дә үзенә күрә бер җылылык иңдерә алган. Монда тузанның бөртеге дә юк. Күршеләр керсә, туганнар килсә дә, рәхәтләнеп шунда сөйләшәләр икән. Гөлзадә апа монда әдәби китаплар да укый.

– Янкорма төзедек тә бер бүлмәдә музей ясарга булдык. Йокларга да, ашарга да, ял итәргә дә бүлмәләр күп. Тормыш иптәшем белән хирысланып, янып-көеп эшләдек. Ул чакта берничә генә экспонат бар иде, – ди 64 яшьлек гаилә башлыгы Равил абый. – Иң беренче булып авылдагы чормадан без – биш бала тирбәлеп үскән бишекне алып төштем. Аннан иске телевизорга чират җитте. Хатынның иптәш кызлары – укытучылар. Алар безгә ике яктан шәҗәрәне ясап бирде. Фотоларыбызны эшләттек. Мин экспонатлар җыйдым. Бала караватын чистартып буядык. Сәгатьне хатынның әтисе Әдһәм бизәгән. Элеккеге көзге, самавырлар, чуен, комган, көянтә... Өчаяк дип аталган казан да бар. Керосин лампасы да – үзебезнең авылныкы. Кыскасы, кайчандыр сарайда аунап яткан әйберләрне җыйдык. Ике улыбыз да Казанда яши. Алар да нәрсә күрсә, шуны алып кайталар. Музейны бергәләп баетабыз.

Сүзгә Гөлзадә апа кушылып: «2011 елда Казанга бергәләп милли архивка бардык. 1922 елга кадәр муллалар язып биргән мәгълүматны табып була әле. Ә аннан соңгы чорны үзебез дә беләбез. Ел саен икебез дә эзләндек. 1883 елгы бабайларны таптык, альбомнар ясадык. Ике улыбыз, биш оныгыбыз бар. Аларның гаиләләрендәге фотосурәтләрне җыйдык. Ике әнинең дә күлмәкләрен, милли киемнәрен элдек. Зәвык белән киенә белгәннәр алар. Әнием Рәсимә 94 яшькә кадәр гомер кичерде. Минем әле тагын бер хыялым бар – милли хатын-кыз образын булдыру. «Күтәртмәле чабата китерәм», – диде берәү. Чиккән алъяпкыч ябып эшлисем килә аны.

Музейда бабалары рухы да саклана. Равил абый әтисенең бертуганнары Әлтәф, Җамали, Кыям абыйларын хәтерләми дә инде. Алар өчесе дә сугышта катнашкан. Ике абыйсы хәбәрсез югалса, Кыям абый бер аягын өздереп кайткан. Аны Кызыл Тау колхозы рәисе итеп билгеләгәннәр. Иң күп уңыш алган өчен, Мәскәүгә делегат булып, съездга барган хәтта. Тик 1946 елда, аягына үлек җыелып, бакыйлыкка күчә. Курса мәктәбендә Кыям абыйның истәлегенә тарихи почмак булдырганнар. Бер караганда, киштәләрдә урын да калмаган кебек. Әмма Сәләховлар, аны элегрәк оештырырга кирәк иде, дип кайчак үкенеп тә куя. Ни өчен дигәндә, борынгы экспонатларны табу җиңел түгел. Ашлык ярыр өчен агач тегермән, май яза торган кисмәк, җеп эрли торган җиһазларның берсе дә сакланмаган. Кемдер тимер-томырга ыргыткан, күрәсең. Тарихи ядкәрләр кадере яшь барган саен ныграк искә төшкән. Хәзер әлеге бүлмәне тагын да киңәйтергә исәпләре.

Гөлзадә апа белән Равил абый тарих укытучысы да, музей хезмәткәре дә түгел. Хуҗабикә ягулык салу станциясендә – оператор, Равил абый «Сельхозхимия»дә 11 ел шофер булып эшләгән. Аннан 12 ел шул оешманың ярдәмче хуҗалыгын җитәкләгән. Яңасала колхозына рәис итеп билгеләгәннәр. Инвесторлар килгәч, электр челтәрендә эшләп, лаеклы ялга чыккан. Җитәкчелек итү каннан киләдер, күрәсең. Әтисе Наил башта – бригадир, аннан агроном, авыл советы рәисе, парторг булган. Тик, кызганыч, 50 яшьтә гомере өзелгән. Әтисен бик зурлап искә алды Равил абый.

– Үткәннәрне белмәгәннең киләчәге юк, дип бик дөрес әйтәләр. Рухи байлык бит бу. Һәркайсын оныкларга җиткереп каласыбыз килә. Аларны музейларга йөртәм. 17 яшьлек Эльвина өйдәге экспонатлар турында кызыксына инде. Оныкларның калганнарында да бу хисне уята алырбыз дип ышанам, – ди Гөлзадә апа.

Сәрия МИФТАХОВА

Телефонга вакыт юк

Авыл тормышы

Кечкенә дә төш кенә! Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында укучы Гөлия Хафизова турында укытучылары әнә шулай диде.

– Авылым Иске Мәңгәрне бик яратам. Әнә шуңа да шәһәргә китмәдем, – дип каршы алды безне 17 яшьлек кыз. – Тугызынчы сыйныфны тәмамладым да техникумга укырга кердем. Казанга да барып карадым. Әмма шәһәр ыгы-зыгысы ошап бетмәде. Әтием –фермер. Күп итеп маллар тотабыз,16 баш сыерыбыз гына бар. Әле алар янында иткә дигән үгезләр, бозаулар да җитәрлек. Шуңа күрә кечкенәдән кул арасына кердем. Әби-бабай тәрбиясе инде бу. Алар да – хезмәттә. Бабам – умартачы. Кулы алтын. Бөтен эш коралын үзе ясый, үзе төзәтә. Әбием газ плитәсе тирәсендә кайнаша, пешекчелеккә укысам да, әле миңа ул эшне тапшырасы килми. Кортын, эремчеген дә үзе ясый, әтием шәһәргә алып барып сата.

Гөлия 15 яшендә сыер сава башлаган. Әни бер тапкыр гына күрсәтте, мин дә кабатлап сорамадым, дип искә ала хәзер ул хәлләрне.

– 16 сыерны саварга 2 сәгать вакыт кирәк. Бер сыердан уртача 10 литр сөт алабыз. Аппарат белән саусак та, ахырдан һәрберсен кул белән дә савып чыгабыз. Җилемдә сөте калмасын өчен шулай эшлибез. Әгәр кала икән, мастит була. Маллар тәрбия һәм кадер күрсә генә авырмый.

Гөлиянең ни өчен трактор йөртергә укыганын да сораштык. Баксаң, әтисенә ярдәм итәргә дип рульгә утырган икән:

– Пешекчегә укысам да, безнең техникумда өстәмә һөнәр алып чыгарга була. Фаил абый янына бардым да трактор йөртергә укыйсы килүемне әйттем. Укыттылар. Өйдә тракторлар күп. Менеп утырып кабызуга, минеке икәнен аңладым. Менә хәзер машина йөртергә дә укый башладым.

Яшелчә бакчалары да зур Хафизовларның. Бөтен эшкә дә җитешергә тырышабыз, ди алар. Бакча күбрәк Гөлиянең әнисе Гөлнур өстендә. Буш вакыты булганда, кыз әнисенә дә булышырга җитешә.

– Балаларга хезмәт тәрбиясе җитми. Күпме күзәткәннән соң шундый фикергә килдем. Безнең гаиләдә бу дөрес оештырылган. Эшли дә, ял итә дә беләбез. Әле менә авыл Сабан туен гөрләттек. Бездә «Кем тизрәк басмага йөгереп керә» дигән уен бар. Шунда әби белән икәү җиңдек. Әле кешегә кызык булсын дип йөгереп тә киләбез, суга да сикерәбез. Бөтен яме шунда инде аның. Быел мин – беренче, әби – икенче, энем дүртенче килде.

Гөлиянең заман яшьләреннән тагын бер аерылып торган ягы бар. Ул социаль челтәрләрдә теркәлмәгән. Телефон тотып ятуның эш калдырганын белә ул.

– Әтием көчле булырга, бирешмәскә өйрәтте. Гел беренче урыннар яулавым – аның үрнәгендә. Әбием дә бик тере. Күпләр мине аңа охшатып, Мәгъфира кызы, ди. Әниемнән сабырлыкка өйрәнәм. Безнең гаиләдә аңлашу бар. Кызып китсәң, утны сүндерүче су да бар, күккә дә чөяләр, җирдән дә аерылмыйбыз, бик тату яшибез, – ди Гөлия. – Безнең кебек үкенмәслек итеп яшисегез килә икән, эштән курыкмагыз!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯЗМЫШЛАР КИСЕШКӘНДӘ

Ягулык салу станциясе – юллар һәм язмышлар кисешә торган урын. Бирегә һәркем үз уйлары, проблемалары, дөньяга карашы белән килә һәм һәрберсе үз юлын табарга тели. «Татарстан – Яңа Гасыр» каналы сериалының фәлсәфәсе әнә шундыйрак. «Юллар чатында» сериалында вакыйгалар республикадагы ягулык салу станцияләренең берсендә бара. Төшерү мәйданында «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

«Бер-бер хәл» һәм «Алмаш» сериаллары тамашачы мәхәббәтен яулап өлгергән иде инде. «Юллар чатында» алардан ким булмаячак, дип ышандыра авторлар. 20 серияле сериал Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Татнефть» хәйрия фонды ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Аны «Ватан XXI гасыр» кинокомпаниясе әзерли.

Бераз сюжетына тукталыйк. «Татнефть» ягулык станциясе күптөрле язмышларның, кызыклы шәхесләрнең очрашу урынына, гел каядыр ашыгучы юлчыларның бераз тукталып фикер туплый торган тынычлык утравына әверелә. Кыска гына вакыт эчендә АЗСта тулы бер гомер үтә: кешеләр кавышалар да, аерылышалар да, табышалар да, югалалар да.

– Сериалны юкка гына «Юллар чатында» дип атамадык. Барыбыз да юлда йөрибез, ягулык салу станциясен дә урап узмыйбыз. Статусына, кем булуына карамастан, барысы да шунда туктала. Еш кына кызыклы хәлләр дә килеп чыга, – диде сценарий авторы Альберт Шакиров.

Аның әйтүенчә, Татарстан өчен ягулык темасы һәрвакыт актуаль һәм әһәмияткә ия.

– Дөресен генә әйткәндә, без аны сизмибез генә. Ләкин сыйфатлы ягулык, аның тирәсендәге инфраструктура барыбызга да кагыла. Уңайлык ягыннан да, шушындый проектлар ягыннан да. «Татнефть» ширкәте белән берлектә, аларның ярдәме белән эшли торган беренче генә сериал түгел бу. Шуңа күрә без монда ул якның да «эчке кухня»сын тамашачыларга күрсәтергә булдык, – диде сценарий авторы.

Тәнкыйтьлиләр икән, димәк, йөрәккә үтә. «Татарстан – Яңа Гасыр» каналы җитәкчесе Илшат Әминов әнә шулай диде.

– Моңарчы төшергән сериалларыбыз барысы да уңышлы булды. Аларны рәхәтләнеп карыйлар һәм безгә язалар, күп хатлар алабыз. Дөресен әйтергә кирәк, тәнкыйтьлиләр дә. Бу бик әйбәт, минемчә, димәк, ул кешенең йөрәгенә үтә. Мондый команда булганда, бу сериал да уңышлы булачагына һич шигем юк. Сериал фәлсәфи, тормыш турында. Һәр кеше бу тормышта үз юлын табарга тели, кемнәрдер белән очраша, талаша, таныша, тормышын кора. Бәлки, моңа охшаш сериаллар инде булгандыр да. Әмма безнең үзенчәлек – ул безнең җирдә, үзебезнең кешеләр белән төшерелгән.

Татар кешеләре чит ил сериалларыннан туйды, дигән фикердә Илшат Әминов. Безнең төп бурыч – үзебезнең кино индустриясен булдыру:

– Мин әле һаман киләчәктә үзебезнең кино индустриясе булыр дип өметләнәм. Аны профессионаллар кулына тапшырып, үзебезгә елга 3–4 сериал, берәр кино төшерү максатларын куябыз. «Татнефть» акционерлык җәмгыятенә бик зур рәхмәт. Алар белән хезмәттәшлектә бу индустрияне булдырырбыз дип өметләнәбез. Кино-сериалларыбызның сыйфатларын яхшыртып, бөтен Россия, дөнья базарына чыгу хыяллары да бар, – диде ул. – Татар кешеләре чит ил сериалларыннан туйды инде. Аларга үзебезнең сериаллар кирәк. Яңа сериаллар төшереп, аларны куандырыпмы, уйлатыпмы, елатыпмы, ничек булса да алга алып барырга кирәк. Телебезне саклауда да бик мөһим бу, – диде ул.

Хәзер инде актерларга күчик. Сериалда төп рольләрне Татарстанның халык артистлары Илдус Әхмәтҗанов, Искәндәр Хәйруллин, Чаллы һәм Әлмәт татар дәүләт драма театрлары артистлары Зөлфия Галиуллина һәм Раушан Мөхәммәтҗанов башкара.

Булат ролен башкаручы Раушан Мөхәммәтҗанов кинода төшү турында күптән хыялланган:

– Ниһаять, кастингка чакырдылар һәм төп герой роленә сайладылар. Булат образы миңа бик якын, кайбер яклар белән охшаш та без. Алмаз абый Әкбәров (сериалның режиссеры) белән бик яхшы аңлашабыз. Аның нәрсә әйтергә теләгәнен шунда ук отып алам. Дөресен әйтим, спектакльләрдә дә бик күп эләгә миңа «тискәре» рольләр. Кыяфәткә, характерга карап бирәләрме икән – белмим. Биргәч, уйныйсың инде, – диде ул.

Ягулык салучы ролен башкаручы Камал театры артисты Рәдиф Галимов та рольне, үземә туры китереп сайлаганнар, ди:

– Тормышта позитив, бар нәрсәдән кызык таба торган персонажларның берсе ул. Шуңа миңа үземә дә эшләве бик күңелле. Халык бик яратып карар дип уйлыйм. Кызыклы вакыйгалар бик күп була. Көлдерер дә, елатыр да.

Төп хатын-кыз ролен башкаручы Зөлфия Галиуллинага исә үзенең роле берникадәр яңалык булган. Беренче тапкыр лирик героиняны уйныйм, ди ул:

– Фильмда беренче тапкыр төшәм. Шундый зур кинопроектта төп рольне башкару зур җаваплылык та, горурлык та. Образга килгәндә, Жасмин карьера дип шаша, шул ук вакытта җан тынычлыгы, мәхәббәт турында да хыяллана. Ничек кенә карасак та, хатын-кызга үз пары белән гаилә кору бик мөһим. Героинямның кайбер сыйфатлары минеке белән тәңгәл, шуңа уйнавы кызык та. Театрда, гадәттә, минем характерлы образлар. Эшләү дәверендә беренче тапкыр лирик героиняны уйныйм. Сериалның сценариен укыганда ук бик ошаткан идем. Халыкка да ошар дип уйлыйм. Чөнки монда бер ир-ат һәм хатын-кыз язмышы гына түгел, монда һәркем үзен табачак. Монда ата белән бала мөнәсәбәте дә, мәхәббәт, эш, үз-үзеңне эзләү дә – бар да бар.

Сериалны көз көне күрсәтергә ниятлиләр.

Ләйсән САФИНА

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Авыл моңсу. Көтеп алган
Сабан туе үтте.
Кичә генә гөрләп торган
Ыгы-зыгы бетте.
Шәһәр халкы ашык-пошык
Җыена да китә,
Сөт-каймагы, йомыркасы
Хәзер күпкә җитә.
Урамнарда тик сәрхушләр
Йөри шыңшып, җырлап,
Очраганнан, баш төзәтик,
Диеп, катык сорап.
Ә Сабантуй мәйданында
Бии җилләр генә,
Буш колгага җылынырга
Чикерткәләр менә.
Авыл моңсу. Бәйрәм узды.
Соры болыт күктә.
Кемнеңдер күңелендә
Сүрелмидер үпкә.
Дәвамы юк бу бәйрәмнең,
Җитте яме, сые.
Имин булсын дөньялары!
Булыр Сабан туе!

Мирһади РАЗОВ

Мач әйткән!

Станислав ЕЖИ ЛЕЦ, поляк язучысы:

– Нульләрдән чылбыр ясарга уңайлы.



Булган хәл

«САЛАВАТ» УЕНЫНА – САЛАВАТ

«Салават Фәтхетдиновның җор теллелеге, тапкырлыгы аерым фәнни эшкә лаек», – ди Айваз Садыйров. Бу хәлне аңа таныш бер артисты сөйләгән.

Шулай бервакыт Салават Уфада концерт куя икән. Шул ук вакытта «Ак барс» белән «Салават Юлаев» хоккей уены бара, ди. Салават чыгышы арасында сәхнәдән исәпне әйтеп, матчның барышы турында сөйли. Соңыннан Уфа командасы оттыра. Салават «Ак барс»ның җанатары икәнен барыбыз да беләбез. Уен нәтиҗәсен башкорт тамашачысына ничек кенә «политкорректно» әйтергә? Зал артисттан соңгы нәтиҗәне көтә бит. Ул елны ике командада да фин легионерлары күпләп уйнаган чак. Салават нинди очракта да Салават инде ул. Чыккан да, гадәттәгечә кеткелдәп, кулы белән борынын сыпырып алган да болай дигән: «Анда безнең финнар сезнең финнарны җиңгән!..» Халык маэстроның тапкырлыгына озак кул чапкан, ди.



Фотомәзәк

ЦРУ смартфоннарга вирус җибәреп, Россиядәге миллионнарча кешенең шәхси мәгълүматына ия булган.

Очлы күзәтүләр

✓ Әни булу ул – өч көн элек чүплек чиләгенә ташлаган уенчыкны балаңа эзләргә булышу.
✓ Йокыны көйләр, дөрес туклану, нервыларны саклар, үзеңне яхшы хис итәр өчен нибары эшкә йөрмәскә генә кирәк икән бит!
✓ Акыллы гаджетлар, акыллы сәгатьләр, акыллы йортлар күбәйде. Акыллы кешеләр генә кими бара.
✓ Әгәр дә эшкә урнашканда сездән стресска мөнәсәбәтегез турында сорыйлар икән, димәк, алар сезне инде уйларында эшкә батырган.
✓ Тешләремне тигезлим дип 30 яшьтә брекетлар кия башлаган кешеләрнең инде гадәттә чәчләре коела башлый.
✓ Бүген психологта булдым. Минем эчемдә 24 төрле кеше яши икән. Ә коммуналка өчен бер мин генә түлим.

«Үпкәсез туй»

МАРСЕЛЬ ӘХМӘДУЛЛИН ЧҮТТӘН ГЕНӘ КАЛГАН

Марсель Әхмәдуллинны күпләр «ТНВ» каналы журналисты буларак белә. Ул анда балалар һәм яшьләр тапшыруларын алып бара иде. Берничә ел элек Марсель телевидениедән китте һәм, сакал үстереп, түбәтәй киеп, дини мәҗлесләр алып бару эшенә чумды. Хәмерсез туйлар, юбилейлар, корпоративлар бүген тансык түгел. Аларны да күңелле итеп оештырырга була. Шундыйларның берсе турында Марсель «Ха-ха-ханә»гә сөйләде.

Никах мәҗлесе бара. Үгет-нәсыйхәт белән бергә уен-көлке үрелгән. Уен белән мавыгып киткән бер мәлдә яулыклы бер әбекәй Марсельнең колагына нидер әйтергә үрелә. Нәрсә әйтмәкче була икән дисә, «Улым, тәһарәтемне боздыртасың бит», – ди әби. «Бу сүзләрне ишетеп, чүт кенә үземнең тәһарәтем бозылмады», – дип көлеп искә ала Марсель Әхмәдуллин.

Әз-мәз мәзәк

– Алло! Исәнмесез! Сез безнең ритуаль хезмәтләр агентлыгына мөрәҗәгать иткән идегез. Яңа хезмәтләргә бары тик 30 июньгә кадәр сезгә 10% ташлама каралган.

* * *

– Кайвакыт ялкауланып алам.
– Ә мин кайвакыт активлашып алам. Ә ялкаулык – минем даими халәтем.

* * *

Егет әйтте – егет эшләде.
Ир әйтте – эшләп карады, бик үк килеп чыкмады, эшләп карамады түгел, эшләп карады, ну ярый инде, килеп чыкмады, дип үлеп булмый бит инде хәзер.

* * *

Мин Акбайны «Сөйкемле хайван» бәйгесенә алып бардым һәм беренче урын алдым. Акбай икенчегә калды.

* * *

Юк эш белән шөгыльләнәм дигән уйлар керә кайвакыт башыма. Аннары моның өчен хезмәт хакы алуым исемә төшә дә тынычланам.

* * *

Вакытны белергә дип телефоныма күз салган идем, бөтен нәрсәне карап чыктым, вакытны карарга онытканмын.

* * *

– Лилия, син тазаргансың икән бит!
– Ә мин авырмадым да.

МӘХӘББӘТ ШУШЫДЫР, ШУШЫДЫР

Без хатыным белән бер-беребезгә шулхәтле туры килмибез, хәтта «Пятерочка» кассиры да безнең тауарларны «следующий покупатель» дигән язу белән аерып куя.

❤❤❤

– Официант, сез өч кешелек счет алып килгәнсез. Без бит икәү генә.
– Күрше өстәлдән сезне күзәткән хатыныгызның да тамагы ач иде.

❤❤❤

– Мин сине ничек танырмын соң?
– Өстемдә – Диор күлмәге, кулымда ак Луи Виттон булыр.
– Ой, мин килмим.
– Нигә?
– Мин сине күтәрә алмам.

❤❤❤

Әгәр дә кемдер синең төшеңә керә икән, димәк, ул синең турында уйлый, диләр. Гаҗәп, Салават Фәтхетдинов бүген төнлә ник минем турыда уйлады икән?



Кино, кино, киная

Узган «Ха-ха-ханә»дә совет киноларындагы сәерлекләр турында язган идек. Бүген дәвам иттерәбез.

«Берегись автомобиля»ны бер ун тапкыр карагансыздыр. Унберенче карауда менә шушы мәлгә игътибар итегез әле: Деточкин барга шакмаклы күлмәктән керә дә бөтенләй башка күлмәктән чыга.

«Белое солнце пустыни» фильмында күләгә әле бер якта, әле икенче якта. Туктагыз әле, бу эпизодны төшергәндә актер ярты көн шулай чүлдә утырган булып чыга түгелме? Ничек исән калган ул?!

Штирлиц машинада йоклый. Ә арткы фонда 1962 елда җитештерелә башлаган «ЗИЛ-130» йөк автомобиле. Сүз дә юк, Штирлиц – маскировка остасы. Әмма «ЗИЛ» барысын да «сатты».



«Девчата» киносын да яратмый мөмкин түгел. Ул кешеләре, ул табигате, ул реквизитлар! Бер реквизит аеруча игътибарны җәлеп итә: ул кадр алышынган саен урыннан-урынга күчеп йөри.

Җәйгә кулыңны җәй!

Үскәч тә җәй шул ук җәй инде ул, әмма каникулсыз.

– Ох, беләсеңме, ул шундый кайнар!
– Ярар инде, мактанма, безгә дә бер атнадан бирерләр җылы суны.

Бу җәйне фитнес-клубка йөри башларга теләвемә 5 ел тулды.

Казанда:
– Ой, юк, мин ул кофейняга бармыйм, андагы каһвә миңа бер дә ошамый.
Авылда:
– Растворимыйммы? Сал әйдә ике кашык!

Элекке заманда календарьлар булмаганда җәй белән кышны «Оливье» салаты буенча билгеләгәннәр. Майонезлы булса – кыш. Куаслы булса – җәй.

Сине диңгездә дип уйласыннар өчен бакчада фотога төшәргә ничек кенә әйбәт ракурс табарга?

Иң шәп ял урыны – дача. Чүп утап арыдыңмы, бераз рәшәткә буяп ял ит. Рәшәткә буяп ялыктыңмы, бераз су сибеп хәл ал.

Тиздән көзге депрессия. Аңа җәйдән үк әзерләнә башлагыз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 285

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+